ГРИФ ХӘЙРУЛЛИН:
«Мин татар икән, ничек итеп бүтән халык булыйм инде?»

> 6–7

АКЧАГА БАЛА?
Россиядә суррогат әниләргә хуплаучылар арткан

> 16

ФЛЕРА ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА:
«Язучыны аңлап, кем кадерләгән?..»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 142 (28724) | Җомга | 1 октябрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

Илдар Мөхәммәтҗанов

ВИРУС ЧИТЛЕГЕНДӘ

КОРОНАВИРУС АВЫЛ КАПКАЛАРЫНА ЙОЗАК САЛА

Авыллары белән авырыйлар. Соңгы арада Татарстанның төрле якларыннан шундый хәбәрләр килеп тора. Йортлары, урамнары белән авыручылар күп. Коронавирус «шәһәр чире» генә булудан күптән узды инде. Соңгы арада исә авыручылар саны да, аны авыр кичерүчеләр, үлүчеләр саны да арта бара. Хастаханәләрдә буш урыннар юк. Чир яшьләрне аяктан йога. Авырлы хатыннар, балаларны аямый. Авылларда исә вазгыять рухи авырлык та өсти: күршеләреңнең гомер буе ачык торган капкасы ябылсын әле! Аның каравы зират капкасы ешрак ачыла башлады...

> 5

Ишетми калмагыз

Күперләр тоташтыра

М12 трассасының Мәскәү – Казан өлешендә 300дән артык күпер һәм җәяүлеләр кичүе төзеләчәк. Әлеге мәгълүматны «Автодор» хезмәте хәбәр итә.

Ока елгасы аша М12 проекты кысасында өч махсус һәм бердәнбер, трослар (вантлар) ярдәмендә беркетелгән асылмалы күперне торгызу өчен технологик күпер төзелеше тәмамланып килә. Кичүнең гомуми озынлыгы 1,3 чакрым тәшкил итә. Ул 17 терәккә салыначак. Асылмалы күпер Ока елгасының Владимир һәм Түбән Новгород шәһәрләрендәге ярларны тоташтырачак.

Татарстанда Идел елгасы аша салыначак күпернең исә озынлыгы – 3362 метр, авырлыгы 45 мең тоннаны тәшкил итәчәк һәм ул М12 трассасының иң зур инженерия корылмасы булачак. Төзелеш өчен беренче блок кирәк-ярагын республикага кайтарганнар инде. Аны 32 айдан кулланылышка тапшырачаклар.

Минималь хезмәт хакы арта

Россия Хөкүмәте Дәүләт Думасына минималь хезмәт хакы күләмен (МРОТ) 6,4 процентка арттыру турында закон проектын тәкъдим итте. Шулай итеп, 2022 ел башыннан ул 13617 сумны тәшкил итәргә тиеш булачак.

Закон проектыннан аңлашылганча, бу сумма 2020 ел өчен медиана рәвешендәге хезмәт хакы (Россиядәге хезмәткәрнең уртача статистик хезмәт хакы) күләменең 42 процентын тәшкил итә. МРОТ күләмен үзгәртү 2,7 млн кешенең хезмәт хакын арттыруга китерәчәк.

Искәртеп үтик: хәзерге вакытта Россиядә МРОТ күләме аена 12792 сумны тәшкил итә.

Әбиләр чуагын көтәсеме?

Казан федераль университеты белгечләре октябрь аена һава торышы нинди буласын сөйләде.

Быел көз халыкны кыска вакытлы җылы һава торышы белән сөендерде. Октябрь аенда инде әбиләр чуагын көтмәскә дә була, ди белгечләр. КФУ профессоры Юрий Переведенцев хәбәр иткәнчә, барыбыз да белгән әбиләр чуагы, гадәттә, сентябрь урталарында килә иде. «Хәзер башкаладагы уртача температура 8,8 градусны тәшкил итә, октябрь башында ул 8 градус булачак, ә аннары акрынлап нульгә кадәр төшәчәк», – ди профессор.

1 октябрьдә Татарстанда алмашынучан болытлы һава көтелә, урыны белән кыска вакытлы яңгыр явачак. Минималь һава температурасы төнлә +2...+7 градус, ә көндез максималь һава температурасы +8...+13 градус булачак. КФУ белгечләре әйтүенчә, октябрьдә уртача температура 4,8 градусны тәшкил итәчәк.

Районнарда ни хәлләр?

Яңа Чишмә

Татарстанның 100 балалар бакчасы һәм 100 мәктәбе тел, гореф-гадәт һәм мәдәниятләрне саклау өлкәсендә белем бирү оешмаларына ярдәм итү буенча грант алган. 500 мең сумлык грант отучылар арасында Яңа Чишмәнең «Алтын ачкыч» балалар бакчасы һәм Зирекле лицее да бар. «Безнең балалар бакчасы күпмилләтле. Анда тәрбияләнүче 102 баланың 33е – татар, 58е – рус, 2се – үзбәк, 9ы – катнаш никахтан туган балалар. Әлеге грант – безнең балалар бакчасына бик зур ярдәм. Аңа заманча интерактив җиһазлар, логопед кабинеты, милли костюмнар, рус һәм татар язучыларының әдәби китапларын, төркем тәрбиячеләре өчен ноутбуклар, музыкаль инструментлар сатып алырга планлаштырабыз. Бу – икенче грант, беренчесен без өч ел элек «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» буларак алдык һәм киләчәктә без бу юнәлештә эшне дәвам иттерәчәкбез», – ди балалар бакчасы мөдире Любовь Михеева.
(«Яңа Чишмә хәбәрләре»)

Апас

Район «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсында призлы урынны алды. Бәйге дүрт номинация буенча үтте, шәһәр һәм авыл җирлекләре арасында җиңүчеләр билгеләнде. Апас шәһәр җирлекләре арасында «2021 елда шәһәр төзелеше сәясәте, халыкның уңай яшәү тирәлеген тәэмин итү һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү» номинациясендә икенче урынга ия булды.
(«Йолдыз»)

Балтач

28 сентябрьдә Куныр авылында яшәүче Зөлхәбирә Нәбиевага 95 яшь тулды. Юбилярга Россия Президенты Владимир Путинның котлау хаты һәм район башлыгы Рамил Нотфуллиннан истәлек бүләге тапшырылды. Зөлхәбирә апа – тумышы белән Түбән Субаш кызы. 1950 елда Куныр авылына килен булып төшә. Фронтовик Галимулла исемле егет белән гаилә корып, 6 кыз, 2 малай тәрбияләп үстерәләр. Кызганыч, бер уллары вакытсыз вафат булган. Галимулла абый 1992 елда бакыйлыкка күчкән. Зөлхәбирә Нәбиева Бөек Ватан сугышы ветераны хөрмәтенә салынган йортта төпчек кызы Зөлфия белән яши. Аның 15 оныгы һәм 22 оныкчыгы бар.
(«Хезмәт»)

Алабуга

Хлыстово авылының физкультура-сәламәтләндерү комплексында футбол буенча матч узды. Уеннар «Экстремизмга – юк!» айлыгы кысасында оештырылды, актив яшь мөселманнар һәм православ яшьләр ярышты. Мондый спорт уеннары инде дүртенче ел рәттән оештырыла. Барлык яшьләр дә – шәһәр мәчетләренә һәм храмнарына йөрүче мәхәллә кешеләре, шулай ук дини оешмаларның актив эшлекләре. Бу – спорт ярышы гына түгел, ә диннәр һәм милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгыта торган чара да.
(«Алабуга нуры»)

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

tatarstan.ru

ҖЫЛЫ, УҢАЙ һӘМ БУШЛАЙ

Билгеле булганча, Россиядә шәхси йортларда газны бушлай тоташтыра башладылар. Әлеге проектка Татарстан беренчеләрдән булып кушылды. Кичә Биектау районының Пермяки авылындагы йортларны да газга тоташтырдылар. Тантаналы чарада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Газ көйли торган пункт 2019–2023 елларда Татарстанның торак-коммуналь хуҗалыгы, сәнәгать һәм башка оешмаларны газлаштыру төбәк программасы кысасында сафка баскан иде. «Газпром трансгаз Казан» җәмгыяте әлеге объектны вакытыннан алда, хәтта бер елга иртәрәк эшләтеп җибәрде. Җир кишәрлекләре чикләренә кадәр меңләп тирәсе газүткәргечләр төзелгән.

Үз чыгышында Рөстәм Миңнеханов әлеге вакыйганың авыл халкы өчен бик зур әһәмияткә ия булуын билгеләп узды.

– Өйдә газ булу җылы, уңайлы һәм даимилек дигәнне аңлата, – диде Президент.

Ул газчыларга 944 хуҗалыкны газга бушлай тоташтыру мөмкинлеге тудырганнары өчен рәхмәт әйтте.

Әлеге чарада «Газпром трансгаз Казан» җәмгыяте директоры Рөстәм Усманов, Биектау районы башлыгы Рөстәм Кәлимуллин һәм башка җитәкчеләр катнашты.

Шунысын билгеләп узарга кирәк: Россиядә торак йортларны газга бушлай тоташтыруны 2023 елга кадәр төгәлләргә планлаштыралар. Исегезгә төшерәбез: әлеге социаль программа Россия Президенты Владимир Путинның Федераль җыенга еллык Юлламасыннан соң эшли башлады.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов фәнни җәмәгатьчелек вәкилләре, югары уку йорты һәм фәнни үзәк ректорлары белән очрашты. Сөйләшү Татарстан Фәннәр академиясенең – 30, республика академик фәненең 100 еллыгына багышланды.

Рөстәм Миңнеханов белдергәнчә, фән даирәсе вәкилләре өчен бу даталар мөһим санала. Юбилей чараларының Россиядә – фән һәм технологияләр, Татарстанда исә Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елында узуының да мәгънәсе бар.

Президент сүзләренә караганда, республикада фән-мәгариф тармагына ярдәм итү турында карарлар комплексы эшләп килә, фәнни-инновацион эшчәнлекне үстерү өчен инфраструктура сафка баса. Болар арасында технопарк һәм төрле үзәкләр, «Иннополис» кебек проектны аерып әйтеп үтәргә мөмкин.

Рөстәм Миңнеханов Фәннәр академиясенә икътисадның реаль секторы белән турыдан-туры эшләргә кирәклеген искәртте. Ягъни аларга житештерүчеләр һәм шәхси бизнес вәкилләре белән тыгыз хезмәттәшлек булдыру, фәнни тикшеренүләр үткәрүдә чит ил һәм үзебезнең белгечләрнең берләшүен тәэмин итү кирәк.

Фәнни җәмәгатьчелек вәкилләре белән очрашу барышында билгеләп үтелгәнчә, бүген ул республиканың иҗтимагый-сәяси үсешенә, заманча фән-мәгариф сәясәтен формалаштыруга, шулай ук халкыбызның мәдәни һәм рухи традицияләрен саклау һәм арттыру эшенә зур өлеш кертә.

СЕЗНЕҢ ЗИРӘКЛЕККӘ СОКЛАНАБЫЗ

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира ЗАРИПОВАның Халыкара өлкәннәр көне уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Халыкара өлкәннәр көне – өлкән буын кешеләренә зирәклекләре, озак еллар намуслы хезмәтләре һәм республикабызны һәм илебезне торгызуга һәм үстерүгә бәяләп бетергесез өлеш керткәннәре өчен тагын бер кат рәхмәт әйтү өчен менә дигән форсат.

Бүген Татарстан Республикасында 962 меңнән артык өлкән кеше яши. Безнең барлык тырышлыгыбыз өлкән буын вәкилләренең сәламәтлеген саклауга, аларның тормыш сыйфатын һәм гомер озынлыгын арттыруга юнәлдерелгән.

2019 елдан башлап Россиядә «Демография» милли проекты тормышка ашырыла. Аның өлеше булган «Өлкән буын» федераль проектын гамәлгә ашыру кысасында Татарстанның барлык муниципаль районнарында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасы уңышлы гамәлгә кертелгән. «Өлкән кешене тәрбиягә алган гаилә», «Тернәкләндерү һәм карау мәктәбе», «Сиделка» кебек стационарларны алыштыручы технологияләр өлкән яшьтәге кешеләргә һәм инвалидларга өй шартларында мөмкин кадәр озаграк яшәү өчен шартлар тудырырга мөмкинлек бирә.

Республикада ел саен халыкка социаль ярдәм һәм социаль хезмәт күрсәтү системасы камилләштерелә. Шул ук вакытта өлкәннәрнең бер генә категориясе дә игътибардан читтә калмый. Өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасы өлкән яшьтәге кешеләргә социаль хезмәткәр ярдәмен өй шартларында алырга мөмкинлек бирә. Үз-үзләренә хезмәт күрсәтә алмаган 1800дән артык татарстанлы интернат-йортларда яши, алар республикада – 26. Ерак авылларда яшәүче өлкәннәргә кирәкле ярдәм «Мобиль бригада» технологиясе кысасында күрсәтелә.

Моннан тыш, Татарстанда авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны диспансеризация узу һәм скринингләр үткәрү өчен медицина оешмаларына илтүне оештыру буенча эш дәвам итә. Быел «Өлкән буын» проекты чаралары белән 60,3 меңнән артык өлкән яшьтәге авыл халкын колачлау планлаштырыла.

«Демография» милли проекты белән шулай ук 50 һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге гражданнарга, шулай ук пенсия алды яшендәге затларга һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирү каралган. 2020 елда өстәмә һөнәри белем алу хокукыннан 3,5 меңнән артык кеше файдаланган.

Республикада өлкән буын кешеләренең ялын оештыруга, аларның җәмгыятьнең мәдәни, иҗтимагый һәм спорт тормышында катнашуына аерым игътибар бирелә, компьютер грамоталылыгына өйрәтү программалары тормышка ашырыла, пенсионерлар электрон хезмәтләрдән актив файдалана. Бу чараларның барысы да өлкән буын вәкилләрен актив эшчәнлеккә һәм аралашуга этәрүгә юнәлтелгән.

Кадерле әти-әниләребез, әбиләр һәм бабайлар! Сез – безнең өчен чыдамлык, хезмәт сөючәнлек үрнәге, заман һәм буыннарның тере бәйләнеше. Без сезнең зирәклеккә сокланабыз һәм өлкәннәрнең киңәшләренә колак салабыз. Бу бәйрәм көнендә сезгә чын күңелдән нык сәламәтлек, җан тынычлыгы, туганнарыгызның һәм якыннарыгызның ярдәмен тоеп яшәвегезне телим. Озын гомер һәм иминлек сезгә!

ҮЗӘГЕ – ТАТАРСТАНДА

Кешеләргә товарларны тиз арада алу, ә җитештерүчеләргә сату эшчәнлеген киңәйтү мөмкинлеге барлыкка килде. Татарстанда «Озон» маркетплейсы үзәге ачылды. Бу – компаниянең Идел буендагы төп логистик үзәге булып тора. Ачылыш тантанасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Компаниянең бу үзәге көн саен 80 меңләп посылка эшкәртә һәм 5 млн товарны саклый ала. Үзәк 670 кешене эшле итә. Үзәкне ачу белән җирле эшкуарларның маркетплейска чыгуы шактый гадиләшәчәк, халыкка да үз заказларын икенче көнгә үк алу мөмкинлеге туачак.

Ачылыш тантанасында Рөстәм Миңнеханов компаниягә алга таба да бу юнәлештә үсүен теләде.

– Искиткеч объект. 38,5 мең квадрат метр мәйданда 400 меңләп төр эшләнмәләр белән сату итеп була. Безнең өчен иң мөһиме – җитештерүчеләребезнең базарга чыгу мөмкинлеге. Нәтиҗәсен күрәбез: 9 ай эчендә электрон сәүдә әйләнеше биш тапкыр артты. «Озон» һәм «Ромекс Групп» компанияләренә рәхмәтемне белдерәм. Кыска вакыт эчендә шушындый корылмалар сафка басты. Әле киләчәккә планнарыбыз бар. Без электрон сәүдәнең кулланучылары да, катнашучылары да булырга тиеш, – диде республика җитәкчесе.

Моннан тыш бу көнне Яшел Үзәндә «Озон»-ның күпләп сату һәм тарату үзәгенең икенче чираты төзелешен дә башлап җибәрделәр. Әлеге корылманы 2023 елда файдалануга тапшырачаклар. Үзәк 4 га мәйданны биләячәк.

Сүз уңаеннан, Яшел Үзән территориясендәге әлеге корылмалар Моношәһәрләрне үстерү фонды теләктәшлеге белән сафка баса. Фонд директоры Ирина Макиева әйтүенчә, берничә ел элек бу урында буш басудан кала берни дә булмаган.

– Ул вакытта бу территорияләрнең үз тормышы белән яшәвен теләдек. Шул чакта бу максатларга фондтан – 930 млн сумнан артык, төбәк бюджетыннан 350 млн сум акча бүлеп бирелде. Бер-беребезгә ышанып эшләү шушындый нәтиҗәләргә китерде. Хәзер биредә җиденче резидент үз эшен башлады. Алга таба тагын берничә объект ачылачак, Яшел Үзән өчен яңа эш урыннары булачак, – диде ул.

tatarstan.ru

МИЛЕК РӘСМИЛӘШТЕРҮДӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР:

ӨСТЕНЛЕК – ЭЛЕКТРОН ВАРИАНТКА

Росреестрның Татарстан идарәсе, тулысынча кәгазь документлардан баш тартып, берничә төрле электрон проект башлавы турында хәбәр итте. Быел милеккә бәйле яңалыкларның иң зурысы: «дача амнистиясе» озайтылды. «Гараж амнистиясе» дә халыкта зур кызыксыну уятты. Быелдан татарстанлыларга милек килешүләрен башкарып чыгу да җиңелрәк була башлаган. Милек теркәүдәге үзгәрешләр турында журналистларга Росреестрның Татарстан идарәсе җитәкчесе урынбасары Лилия Борһанова сөйләде.

– Әгәр гражданин белән милек килешүе – сату-сатып алу, аренда, дәүләт органнары һәм җирле үзидарәләр белән җир участокларын башка кешегә бүлеп бирү турында кәгазь документ килешүләре төзелгән икән, быелдан аларны рәсмиләштерү җиңеләйде. Бу очракларда дәүләт хөкүмәте һәм җирле үзидарәләр кул куелган документның скан-үрнәгендә аны әзерләргә, расларга һәм шәхси милек хокукларын рәсмиләштерү өчен Росреестрга юлларга тиеш була, – дип аңлатты Лилия Борһанова.

Шул ук вакытта скан-үрнәкне кешенең имзасы белән расларга кирәк булмаячак. Шулай итеп, килешү процессы җиңеләя һәм ачык була. Җитәкче сүзләренә караганда, Росреестр документларның кәгазь вариантын бөтенләй калдырмый.

– Статистика буенча, бездә барлыгы 4 млн тирәсе реестр эше саклана. Ай саен уртача алганда архивка 30 мең эш кабул ителә. Ләкин бүген без 3 миллионга якын эшне электрон вариантка күчердек, – диде ул.

Җитәкче шул ук вакытта күпфункцияле үзәкләргә документларның кәгазь вариантын да кабул итүләрен әйтте. Ләкин аның сүзләренчә, халык көннән-көн электрон вариантка өстенлек бирә. Быелдан шулай ук өстәмә документларны карау вакыты 3 эш көне дип билгеләнгән. Ягъни дәүләт теркәвен башкара торган кеше, документ кабул ителгәннән соң, туктаган эшне башлап җибәрергә һәм берәр карар кабул итәргә тиеш. Җитәкче моңа кадәр исәпкә алынган объектларны ачыклауга кагылышлы федераль закон турында да искә төшерде.

– Әлеге законны тормышка ашыру белән районнар шөгыльләнә. Алар үзләрендә архивны анализлап, кирәк дип тапсалар, мәгълүматларны башка дәүләт органнарыннан соратып алырга тиеш. Шуннан соң карар проектын кабул итеп, үзләренең сайтларында бастырып чыгарырга һәм милекчегә җибәрергә тиеш, – дип аңлатма бирде Лилия Борһанова.

Ике ай эчендә, ягъни әлеге закон гамәлгә кергәннән бирле 51 шундый объект кадастр исәбеннән төшерелгән. 36 объект дәүләт теркәве үткән.

Болардан кала, сентябрьдә Татарстанда ипотека теркәве вакытын кыскарту буенча яңа проект гамәлгә ашырыла башлаган. Казанлылар инде әлеге хезмәттән файдаланырга да өлгергән. Тиз һәм уңайлы юл белән 350 ипотека килешүе төзелгән.

– Әлеге проект кысасында электрон юл белән тапшырылган ипотеканы бер тәүлек эчендә теркәргә мөмкин. Моңа кадәр әлеге эшне башкарып чыгу өчен 5–7 көн кирәк иде. Сигез ай эчендә Татарстан Росреестрына 12 мең мөрәҗәгать кабул ителде. Гомумән алганда, узган ел белән чагыштырганда, электрон ипотекалар саны 5 процентка артты һәм гомуми мөрәҗәгатьләрнең 35,5 процентын тәшкил итә, – диде җитәкче.

Быелдан гамәлгә кергән тагын бер яңалык турында «Росреестрның федераль кадастр палатасы» учреждениесенең Татарстан буенча филиалының директор урынбасары Ләйсән Рәхмәтуллина сөйләде. Аның сүзләренә караганда, быел ЕГРН мәгълүматларын кабаттан сату тыела. Шул исәптән ялган сайтлар ярдәмендә дә.

– Интернеттагы кайбер сайтлар төрле ведомстволарныкына бик охшаш. Мондагы мәгълүматларның дөреслеккә туры килмәвен аңларга кирәк. Кайбер мәгълүматларны дәүләт органнарыннан бушлай да алырга мөмкин булыр иде, тик бу сайтларда алар акчага ясала, – ди җитәкче.

Ләйсән Рәхмәтуллина әйтүенчә, әлеге кабул ителгән үзгәреш кешеләрне ялган мәгълүматлар алудан сакларга тиеш. Кирәкле мәгълүматларны исә gov.ru рәсми сайты, Кадастр палатасының онлайн сервисы аша яки дәүләт хезмәтләре сайтыннан соратып алырга мөмкин.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

Айдар ШӘЙХИН

Мәгълүматлар белән нишләргә?

Соңгы 5–10 ел эчендә бөтен дөньяда мәгълүмат технологияләре бик зур тизлек белән үсеш алды. Технологияләрдә яңарышлар көндәлеккә үтеп керә дә, телебез аларны тасвирларга тиеш була. Бу максатка ирешү юлында хаталар да кылынмый калмый.

Мәгълүмат сүзе үзе үк проблемалар чыганагына әверелде. Беренчедән, аның язылышы күпләрдә авырлык тудыра. Гамәлдәге орфография кагыйдәләренә күрә, аны *мәгълумат* дип тә, *мәгълүмәт* дип тә язарга һич ярамый. Бу сүз телебезгә гарәпләрдән кергән, язылыштагы кытыршылыклар да алынма булуы белән аңлатыла.

Икенче бер мәсьәлә: *мәгълүматлар*. Мәсәлән, менә мондый җөмлә: *Әлеге шәхес турында мәгълүматлар юк дәрәҗәсендә*. Нинди дә булса өстәмә хәбәрнең, хәл-торыш турында булган белем күплеген бу җөмлә авторлары «мәгълүматлар» дип язган.

Эш шунда ки, татар телендә дә, рус телендә «мәгълүмат» – «информация» сүзе күплек санда кулланыла алмый. Ул абстракт төшенчәне белдерә, шуңа күрә аны күбәйтеп булмый. Мәгълүмат үзе күп санлы хәбәрләрдән, тамгалардан, телдән һәм язмача таратыла торган белемнән тора. Аны күбәйтү ысулы – күләмен (эченә кергән элементлар санын) арттыру, ә үзенең санын берничек тә арттырып булмый.

Шуңа күрә татар телендә *мәгълүматлар* дип сөйләшә алмыйбыз. *Дәрестән күп мәгълүмат алдым. Китапта күп мәгълүмат бар*.

Белем сүзе белән дә шул ук хәл. Аны да, абстракт төшенчә буларак, күплек санга кую дөрес булмый. Шулай да, *белемнәр* дип язу бик күптәннән әдәбиятка да, матбугатка да үтеп кергәнгә күрә, бу очракны хата түгел дип әйтергә була.

Сүзне мәгълүмат технологияләреннән башладык. Бәгъзе авторлар бу сүзтезмәгә дә каршы. *Информацион технологияләр* дип язуны гына дөрес дип таныйлар. Алар белән килешәсе килми, татар телендә булган лексик байлыкны актив кулланырга кирәк.

Технологияләр өлкәсендә *данные* төшенчәсе бар. Аны татарчага тәрҗемә иткәндә *мәгълүмат* дип күрсәтү хәерле. Big data – большие данные – татарчага күләмле мәгълүмат яки зур *күләмле мәгълүмат* дип тәрҗемә ителә.

Әйтеп кенә бактым

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Монысы кем тагын?

«Бу дөньяда башыңны җүләргә салып йөрмәсәң бетәсең», – дип еш әйткәлим. Тормыштан зарлану түгел инде бу. Халык кайчан рәхәт чигеп кенә яшәгәндер, тарих аны хәтерләми. «Тормыш – ананың ормыш» дигән сүзләр дә тиктомалдан килеп чыкмагандыр.

Әмма дөнья йөзләрендә шаян сүзле, якты йөзле кешеләр дә бик күп. Алар тормыштагы кайбер күңелсез хәлләрне дә уенга борып, көлеп-шаяртып уздырып җибәрергә тырышалар. Алар – киләчәккә өмет күзе белән караучылар. Алар кеше бәхетсезлегеннән көлмиләр. Алар көлүе – башка төрле көлү, күңелгә рәхәтлек бирә торган көлү.

Яшь чагымда миңа концертлар алып барырга туры килде. Кайда, кемнән ишеткән сүзләр булгандыр, концертны гадәттә: «Дуслар, беләсезме, бер кешенең ха-ха-ха дип көлеп куюы организмга илле грамм ит ашаган кадәр энергия бирә икән», – дигәнрәк сүзләр белән башлый идем. Тамашачы көлә, сүзләремә ышанмасалар да, арада әчләре катып көлүчеләр дә очрый иде. Аларга төртеп күрсәткән булам: «Фәлән рәттә утырган апа шулхәтле ихлас көлде, ул инде илле грамм ит түгел, беләк буе сөяк кимергән кадәр энергия җыеп утырадыр», – дигән булам.

Медицина күзлегеннән караганда, көлүнең организмга файдасы турында уйлап караганым булмады, әмма шаярышкан-көлгән вакытта һәрберебезнең рәхәтлек хисләре кичергәнен сизә идем.

Күптән түгел бер танышым мондый гыйбрәт сөйләде. Ул телгә алган кешенең кайсы районда яшәгәнен, кем булып эшләгәнен, исемен язып тормыйм. Чөнки әлеге гыйбрәт ир белән хатын-кыз арасындагы мөнәсәбәтләргә кагыла. Кыскасы, бер районда шук сүзле бер җитәкче яшәгән. Бер предприятиенең директоры булган ул. Матур кызларны яраткан. Кул астында эшләүче бер чибәргә хәтта фатир да алып биргән. Халык арасында «гүләйт итә» дигән сүз таралган. Җитәкченең «мораль яктан тәмам таркалуына» юл куймас өчен, хатынына: «Сәлимә, узең беләсеңме, ирең синең өстән йөри бит», – дигәннәр. Сәлимә ышанмаган: «Андый кеше түгел ул, мине дә, балаларны да ярата, бик гаилә җанлы», – ди икән.

– Менә шушы минутта иреңнең кайда икәнен беләсеңме соң?

– Эштәдер, кайда булсын.

– Ул хәзер фәлән кыз белән менә шунда, – дип, Сәлимәгә адрес биргәннәр. Киткән инде бу адрес буенча. Күрсәтелгән урын кафе икән. Ярымкараңгылык, әкрен генә музыка уйный. Сәлимә почмактагы бер өстәл янында ирен күреп ала. Тегесе бер кыз белән кара-каршы утырган да, нидер сөйләшәләр. Ире хатынын күреп ала да: «Сәлимә матурым, син түгелме соң бу?» – ди. Җен ачулары кузгала башлаган Сәлимә: «Хатыныңны да танымый башладыңмы әллә…» – дигән сүзләр әйтеп, иренә таба атлый. Ә ире каршында утырган кызга карый да: «Ә монысы кем тагын?» – дигән була икән. Сәлимә аптырап туктап кала да көлеп җибәрә.

Бу вакыйга ничек тәмамлангандыр, белмим, җитәкче абзый үзе дә бакыйлыкка күчкән инде, әмма аның турында бүген дә сагынып сөйлиләр. Бу гыйбрәтне тыңлагач, абзый «мораль яктан таркалган кеше» булып күз алдына килми. «Ә монысы кем тагын?» дигән сүзләре бүген дә телдән төшми, җай чыккан саен көлә-көлә сөйлиләр ди.

Язганнарым хатыны өстеннән йөргән кешене мактау кебек аңлашылмас, шәт. Әлеге абзый белән бер чорда яшәсәм, без аның белән дус та булган булыр идек, бәлки. Күңелсезлекләрне уен-көлке, кайчак күз яше аша көлеп, бергә-бергә үткәреп җибәрер идек.

Минем тагын бер танышым бар әле. Дустым түгел, танышым. Кечкенә бер җитәкче. Ул һәрвакыт йөзенә җитди кыяфәт чыгарып йөрер, телефоннан аерылмас. Хәтта бадрәфкә дә телефон белән кереп утырыр. Хакимият биналарының берсендә бик еш очрашабыз. Инде менә ничә еллар бер мәртәбә дә елмайганын күргәнем юк. Хезмәттәшләре әйтүенчә, гаиләсе тулы, тату, эшен яхшы башкара, кешеләргә тупас түгел. Мин аны гаепләмим, бар булмышы шундый икән, ни хәл итәсең. Ә мин, алда әйткәнемчә, башны җүләргә салып йөрергә яратам. Көлеп яшәү миңа бер дәва сыман. Табиблардан да ишеткәнем бар: көлеп яшәгән кешедә бәхет гармоннары да арта икән. Көлгәндә бит кенә түгел, корсак, күкрәк мускуллары эшли, йөрәккә кан да әйбәтрәк килә ди. Көлгән кешедә хәтта антитәнчекләр дә ишлерәк була, имеш. Ә бүгенге заманда ул бик кирәк нәрсә.

НИШЛӘТЕРГӘ СИНЕ, МӘКТӘП?!

Путин Мәгариф министрлыгына һәм төбәк хакимиятләренә укытучыларның хезмәт хакын күтәрү турында уйларга кушты. Ияләнелгәнчә шулай дип язып куйдым да Путин әмерен яңадан укып чыктым. Юк, күтәрү түгел, ә укытучы хезмәтенә түләү системасын камилләштерү турында бара икән сүз. Безнең баш мие автомат рәвештә аны күтәрү дип кабул итә. Төбәкләр бюджетының бик кысынкы булуын исәпкә алсак, системаның бер үк бюджетны башкача бүлү тарафына гына үзгәртелүе дә ихтимал икәнен аңларга тиешбез. Бәлки, кемнәрдер күбрәк тә ала башлар… Әлегә тумаган тайның билен сындырып булмый, чиновникларның мәсьәләне ничек хәл итүен вакытлар узгач күрербез, мөгаен. Владимир Владимирович кушканнар арасында мәктәпләрдә контроль эшләр санын киметү турындагысы да бар. Балалар кулына әлегә торган интернет-мәгълүматны дәүләт контроленә алу да максат ителәгән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Тагын бер нәрсә игътибарны җәлеп итә: Президент әле яңа гына «Бердәм Россия»нең партия комиссияләрен төзү турында да игълан итте. Парткомиссияләрнең берсе турыдан-туры мәгариф өлкәсен үз канаты астына ала. Тагын берсе «Аналарны, балаларны, гаиләне яклау» дигән исем белән аталган. Монысының да функциясенә тәрбия, мәгариф мәсьәләләре катнашуын аңлау кыен түгел. Дөресен генә әйткәндә, тагын бер яисә берничә бюрократик аппарат булдыру эшкә бик әллә ни ярдәм итәр дип өметләнмим. Өстәл яны фронты сугышчылары саны арту мәктәп өстенә яңа тикшерүләр генә вәгъдә итә. Яңа кәгазьләр тутыру, яңа отчетлар булдыру ихтыяҗы котылгысыз рәвештә көн тәртибенә килеп баса. Һәр яңа министр исә, эшкә кергәндә, отчетлар киметеләчәге, укытучының кирәкмәгән кәгазьләр тутырып мәшәкатьләнүенә юл куелмаячагы турында вәгъдә итә һәм… аннан соң килгән министрга шул вәгъдәне янә бер тапкыр кабатларга туры килә.

Президент командасының сентябрь сайлавыннан соң төп проблемаларның берсе итеп мәгариф өлкәсен күрүе һәм шул өлкәдә инициативалар белән чыгуы гаҗәп түгел. Менә бу соңгы вакытларда мәктәпләрдәге һәм уку йортларындагы атышлар, балалар суицидының бик югары саннары, илнең технологик яктан бик нык артта калуы, вузларда белем алган күп студентларның эш һәм яшәү урыны итеп чит илләрне сайлавы, белгечләрнең компетентсызлыгы, мәктәпләрдә укытучылар җитешмәү… Проблемалар йомгагы таудан төшкән кар йомгагы кебек үсте бит. Аңлашыла инде: Президент администрациясе Мәгариф министрлыгына идеяләр сорап мөрәҗәгать итә. Министрлыкның исә үз коллекциясендә берникадәр идея сакланмый калмый, әлбәттә. Менә бу контроль эшләр санын киметү идеясе – дөрес фикер ул дөреслеккә. Менә шуның ничек итеп Президент идеясенә әверелүенең кухнясын карыйк әйдә. Җәй көне үк инде Мәгариф министрлыгы һәм Россиянең мәгарифне күзәтү органы (Рособрнадзор) мәктәпләрдә бәяләү эшләре санын киметү турында рекомендацияләрне югарыдан түбәнгә төшергән булганнар. Эш бит шунда: бала бер көн эчендә берничә контроль эш эшләргә мәҗбүр хәзерге вакытта. Моның никадәр стресс һәм психикага никадәр һөҗүм икәнлеген аңларга була. Аңа ничек түзәргә кирәк? Әле укытучының пландагы контроль эшләреннән тыш теләсә кайсы вакытта мәктәп администрациясе тикшерү белән кереп утырырга мөмкин, югарырак мәгариф оешмаларыннан килеп төшсәләр дә гаҗәп түгел. Мәктәп өчен бик гадәти хәл. Бу очракта стресс балага гына түгел, укытучыга да яный. Нәтиҗә күрсәтергә кирәк була. Ә ун балалы бер класста 4–5 дислексик һәм дисграфик бар икән, нәтиҗәне ничек итеп күрсәтәсең? Илле процент «икеле» гарантияләнгән, чөнки гадәти мәктәп методикалары белән берничек тә дислексикларны укырга өйрәтә алмыйсың. Аларны өйрәтү өчен махсус технологияләр кирәк. Менә шунда укучылар белән укытучылар бер йодрык булып берләшәләр инде гадәттә. Өскә килгән куркынычны бергәләп уздырып җибәрү җаен табалар. Проблемамы бу? Проблема. Әмма, гафу итегез, Президент дәрәҗәсендә хәл итәлә торган масштаблы түгел. Аны Мәгариф министрлыгы гадәти эш режимында әллә кайчан хәл итәргә тиеш иде инде.

Ил җитәкчесе исә, бу юлларның авторы аңлавынча, глобальрәк мәсьәләләрне хәл итүне гарантияләргә тиеш. Әйтик, ни өчен балаларда фәннәрне үзләштерергә стимул юк? Мотивация юк икән, уңыш юк, ахыргы нәтиҗә песи яларлык кына була. Ни өчен педагогик вузларга сәләте чамалырак булган абитуриентлар гына килә? Аларның да әле бик азы гына мәктәпкә әйләнеп кайта. Гомумән, белгечлек буенча эшләмәү – хәзерге заманның бер чире бит инде. Егет яисә кыз инженер дипломы ала да сәүдә рәтендә басып тора. Яисә башка өлкәгә китә. Бары тик үз белгечлеге буенча гына эшләми. Бу бит инде – югары мәктәпкә салынган инвестицияләрнең үзләрен акламавы дигән сүз. Салым түләүчеләр акчасын суга салу. Менә бу проблемаларны чишәргә тармак министрлыкларының гына көче җитми, чөнки бюджет-финанс мәсьәләләре белән тыгыз бәйләнгән. Аларны хәл итү өчен югары җитәкчелекнең сәяси ихтыяры таләп ителә. Ә безнең белгечләр Президент администрациясе идеяләр сорагач, үзләрен арты белән күлгә чумган үрдәк кебек тоталар: үз югарылыкларында хәл ителергә тиешле мәсьәләләрне төртәләр. Аларның кайберләрен хәтта мәктәп администрациясе дә уңышлы хәл итә алыр иде.

Мәктәптәге атмосфераны үзгәртү генә дә кайвакыт радикаль уңай үзгәрешләргә китерә ала. Бала тормышында бер укытучы революция ясаган чаклар була. Бөек совет педагогы, академик Шалва Александрович Амонашвили дигән шәхес бар бит. Хәзер туксан яшь инде аңа. Милләте буенча грузин ул. Менә шул кеше мәктәптә җиденче класска кадәр тоташ «икеле»гә укыган. Ә мәктәпне алтын медаль белән тәмамлаган. Аның укуга мөнәсәбәтен грузин теле укытырга килгән яшь укытучы кыз үзгәрткән. Бер укытучы бала аңында кискен борылыш ясый ала, димәк. Югары җитәкчелекнең эше исә мәктәпкә ничек итеп менә шундый укытучыларны китерү проблемасын хәл итү булырга тиеш. Калганын шул укытучылар хәл итә инде аның. Югарыдан комачауламасалар, әлбәттә.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Теманың дәвамы 15 нче биттә >

«ВТ» архивыннан

ВИРУС ЧИТЛЕГЕНДӘ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Ышанмаучылар юк хәзер»

Коронавирус белән ике еллап «дус» булсак та, әлеге көтелмәгән кунак турында бар кеше дә ачылып китеп сөйләргә яратмый. Башкалар ни әйтер дип курка, чирләгәнен белгертәсе килми, авыру барлыгына ышанмый – сәбәпләре төрле. Тик кайчагында курку аяныч нәтиҗәләргә дә китерә. Шул ук прививкадан куркуны гына алыйк. Чир йоктырып бакыйлыкка күчү, аны авыр кичерүдән бигрәк вакцина ясатудан ешрак шүрли бугай халык.

Интернеттагы мәгълүматның да йогынтысы юк түгел. Буа районыннан К. ханым прививкадан куркучылар шул сәбәпле күп дип саный. Табиб-белгеч сүзенә ышанганчы, имеш-мимешкә ышану күпкә җайлырак бит. Тик бу гына кешене үз сәламәтлеге өчен җаваплылыктан азат итми. Әңгәмәдәшебез яшәгән берничә йөз кешелек авылда исә коронавирус чирен йоктыручылар да, аннан үлүчеләр дә аз түгел.

– Июнь аенда да бер артып алган иде ул авыручылар. Нәкъ тә шушы чирдән үлүчеләр дә булды. Гаиләләп авырдылар. Җәен ирле-хатынлы гаилә хастаханәдә парлап ятып чыкты. Күпләрне балалары Казанга алып китте, шәһәрдә дәваландылар, терелеп кайтучылар да булды. Тик барыбер авыру эзсез генә үтми бит ул. Шул ук июнь аенда хастаханәдә терелә алмыйча үлүчеләр булды. Өч көн элек кенә ике кешене күмделәр. Алар берсе дә прививка ясаткан кешеләр түгел, – дип сөйләде ул. – Быелтыр да күпләп авырдылар. Кайсылары аяк өсте генә уздырып җибәрде инде. Хроник чирләре булган кешеләр хастаханәдә ятты. Кешеләрнең йөзен күрәсең бит: чирлеләрнең йөзләре каралып китә иде. Авырганлыгыны белгертәсе килми, ә кыяфәтенә карауга ук беленә иде... Безнең авылда халык бердәм. Кабер казышырга да, күмәргә дә кеше күпләп йөри. Тик шушы авыру тарала башлагач, зиратта кеше кимеде... Коронавирустан курыкмыйлар дип әйтеп булмый инде, куркалар. Ышанмаучылар юк хәзер. Күз алдында үлеп торалар бит. Гаиләгә керсә, барысын да егып сала. Коронавирустан үлгәннәрне туры зиратка алып кайтып күмәләр.

Вакцина димәктән, бу авылга аны махсус килеп тә ясыйлар икән. Теләк белдерүчеләр генә берән-сәрән. «Безне берәү дә мәҗбүриләмәде, әмма ирем дә, мин дә коронавируска каршы прививка кадаттык. Алай авырлык сизмәдек», – ди әңгәмәдәшебез. Узган елның июнь аенда ук тормыш иптәше белән чирләп тә алганнар икән. Өйдә генә дәваланып, җиңел генә уздырып җибәргәннәр. «Температура берничә көн 37 тирәсендә торды. Тәм-ис сизмәдек. Балалар кайткан чак иде. Аларга да иярде инде. Тик оныкларыбыз чирләмәде. Балалар эшкә йөрмәде, «больничный» алып, өйдә килеш кенә уздырды. Балалар да прививка ясатты. Табиблар да ясата бит. Бар кеше дә ясатса, бәлки, бу авыру тизрәк үтәр иде кебек. Кемдер авыр кичерә, ди инде. Гади генә уколдан да аллергия булырга мөмкин ул. Былтыр чир кешедә җиңелрәк уза иде кебек. Моннан соң да Ходай сакласын инде. Грипптан да прививка ясатабыз, ел да файдасын күрәбез», – ди К. ханым.

Сакланганны саклый

Азнакай районындагы Карамалы авылында 440 кеше яши. Шушы арада коронавирус зәхмәте бирелдәге халыкны иң кирәкле саналган кешесеннән мәхрүм иткән – фельдшерсыз калдырган. Башкаларга дәва өләшүче шәфкать иясе шушы авырудан үлгән.

– Узган атнада вафат булды. Якшәмбе җирләдек. Аның урынына яңа кеше билгеләнде. Авыл кешесен фельдшерсыз калдыру мөмкин хәл түгел! Салада өлкәннәр күп. Көн саен кайсы укол кадатырга, кайсы система алырга йә башка йомышы белән килә. Үзәк хастаханә бу сорауны тиз арада хәл итте. Яңа медицина хезмәткәре көн дә Азнакай шәһәреннән килеп йөри, – диде авыл җирлеге башлыгы Артур Ногманов. Элеккеге фельдшер шушы авылга 30 еллап хезмәт күрсәткән. Авылдагылар аны яхшы сүз белән генә искә ала.

Халык вирус белән яшәргә өйрәнгән һәм ияләшкән инде.

– Сакланалар, юкка-барга җыелмыйбыз, бәйрәмнәр, концертлар оештырмыйбыз. Авыл советына киләсе булса да, кеше саклану чараларын онытмый. Өйрәнделәр инде, сакланганны саклый бит. Өлкәннәр көне уңаеннан да, гадәттә, чәй табыны әзерли идек. Быел коллектив белән җыелып сөйләштек тә, кибеттән азык-төлек сатып алып, күчтәнәчләр әзерләргә булдык. Битлек-пирчәткә киеп, таләпләрне үтәп, өлкәннәребезнең өйләренә барып таратачакбыз. Ветераннар советы белән дә киңәшләштек, хупладылар, – ди Артур Ногманов.

Вакцина ясату мәсьәләсенә килгәндә, биредә яшәүчеләрнең 90 процентка якыны прививка кадаткан икән инде. «Карамалы авылында әлеге чирдән авыручылар күп димәс идем. Әмма юк дип әйтеп булмый инде. Нигездә, өлкәннәр. Хроник чирләре булган кешеләр тиз бирешә. Коронавирус бит зәгыйфьрәк урыннарыбызны эзли. Аңлату эшләрен алып барабыз. Хәзер авылларның Ватсапта төркемнәре дә бар. Кисәтүләрне шунда да җибәреп торабыз. Халык үзе дә, берүк саклаayык, дип кенә тора», – ди авыл җирлеге башлыгы.

Сүз уңаеннан, Карамалы авылы янәшәсендәге салаларда вазгыять бик үк әйбәт түгел. Берничә чакрым ераклыкта урнашкан Таллы Бүләк авылында атна-ун эчендә чирләп, дүрт кеше үлгән. «Кеше арасына чыгып йөрмәскә тырышам. Безнең авылда вазгыять ул чаклы киеренке димәс идем. Хастаханәдә ятып кайтучылар да, өйдә генә чирләүчеләр дә бар. Алты кешелек бер гаиләдә барысы да чирләп ята», – дип сөйләде Беренче Май авылында яшәүче әңгәмәдәшебез.

Биектау районы Алан-Бәксәр авылы җирлеге биш авылны берләштерә. Җирлек башлыгы Зөһрә Гарифуллина әйтүенчә, салада барлыгы 607 кеше яши. Халыкның күпчелеге коронавируска каршы вакцинаның әһәмиятен аңлап, прививкага уңай карый.

– Вакцинаны Дөбъяз участок хастаханәсенә барып ясаталар. Еракта, урман эчендәрәк урнашкан Гәр дигән авылыбызга район үзәк хастаханәсеннән килеп ясыйлар. Прививканы нигездә өлкән яшьтәге кешеләр кадатты, – дип сөйләде Зөһрә Гарифуллина. – Кешеләрдә, вирус әле безнең илгә килеп кергән генә чорда, курку бик көчле иде. 2020 елның яз-җәй айларында гаиләсе белән карантинда утыручылар күп булды. Авылда гомер бик күрмәгән капкалар бикләнеп, күрше күршегә кермәс булган иде.

Дөрес, салада яшәүчеләр битлек киеп йөрүне онытмый. Онытты рмыйлар да: полиция вәкилләре еш кына килеп, тикшерүләр оештыра. Район җитәкчелеге дә вакцина ясату барышын контрольдә тота. Оешмаларда моның әһәмияте турында сөйләп, аңлатып торалар.

– Коронавирус пандемиясе башланганнан бирле биш авылга өч кеше шушы чирдән вафат булды. Авырып, хастаханәдә ятып кайтучылар булып тора. Бер гаиләдән берьюлы ике-өч кеше чирләүчеләр дә бар, – диде Зөһрә Гарифуллина.

«Яшисе килмәде!»

Балтач районындагы Арбор авылыннан Мадефия Габделхакова коронавирус белән чирләгән көннәрен хәзер куркыныч төш кебек искә ала. Сырхауны үзе генә түгел, туганнары белән бергә кичерергә туры килә. Барысы да хастаханәдә ятып чыга. Чирне кичерү – бер нәрсә, әле аннан соң да тулысынча тернәкләнеп бетеп булмый, ди әңгәмәдәшебез.

– Узган елның ноябрендә чирләдек. Коры ютәл, хәлсезлектән башланды. Тәм дә, ис тә тоймадым. Бер атналап өйдә яттым әле. Аннан Чепья хастаханәсенә төштем, анализлар алдылар. Киләсе атнага килерсең, дигәннәр иде, аңа кадәр көтеп булмады инде, – дип сөйләде ул. – «Ашыгыч ярдәм» белән Арча хастаханәсенә компьютер томографиясе төшерергә алып киттеләр. Үпкәләрнең 40 проценты зарарланган булып чыкты. Дөресен әйтим, минем инде яшисем дә килмәде. Йөри алмаслык хәлгә җиткән идем. Шуннан туп-туры Балтачка, әле яңа ачылган коронавирусны сырхаулар өчен госпитальгә илттеләр. 15 көн ашамадым, су эчеп кенә яшәдем. Шикәр диабеты, аритмия кебек чирләрем дә бар. Бу зәхмәт барлык «йомшак» җирләремә бәрде! Табиб та: «Синең йөрәгеңне дә ишетеп булмый», – диде әле.

Туганнары да чирләде димәктән, Мадефия Габделхакованың ире коронавирусны аяк өсте генә кичерә. Өйдә, үзизоляция шартларында дәвалана. Хастаханәгә исә әңгәмәдәшебез сеңлесе һәм аның ире белән бер көндә керә.

> – Сеңлем белән мин 10 көн дәваланып чыктык. Иптәше әле аннан соң да бер атна ятты. Аңа кислород тоташтырганнар иде, – диде ул. – Мондый хәлдә ятканда яшисе килми икән! Ходайдан, җиңел үлемнәр бир, дип тә сорадым. Чирнең ничек узуы турында кешегә әйтеп-аңлатып бетерерлек түгел! Үзеңне кая куярга белмисең – менә шундый начар хәләт. 70 яшемә җитеп, беренче мәртәбә шулай авырдым. Салкын тиеп тә бу кадәр чирләгәнем юк иде. Бу чир барлыгына ышанырга кирәк. Бик тиз иярә.

Әңгәмәдәшебез дә, ире дә вакцина ясаткан. Балалары киңәш иткән икән.

Тормыш сөйгән кешеләр тизрәк терелә. Чир белән күзгә-күз очрашкан кешеләр моны хәзер яхшы аңлый. Башкаларга да сабак булсын, ди. Балык Бистәсе районындагы Тәберде Чаллысы авылыннан Әхмәтхан ага Вафин да, 91 яшенә җитеп, шушы зәхмәт белән очрашырмын дип һич тә уйламагандыр. Үпкәләренең 25 проценты зарарланган була аның. Хастаханәдә дәвалана. Хәзер инде сәламәтләнеп, өенә кайткан. Вакытында ярдәм күрсәткән медицина вәкилләрен рәхмәтеннән калдырмый Әхмәтхан ага.

– Коронавируска каршы прививканы март аенда – авылымда беренчеләрдән булып ясаттым, – ди ул. Башкаларга да аның әһәмиятен аңлата. – Кешеләрнең нәрсәдән куркканын әлегәчә аңламыйм. XXI гасырда яшибез, барын да телевизор, радиодан ишетеп торабыз бит инде. Үзебез бу очракта заманча медицинага ышанмыйбыз... Ярый әле вакцина ясатканмын, дим. Хастаханәдә мине караган һәркайсына рәхмәт әйтәм. Кайчагында сүз дә дәвалый бит.

Сүз уңаеннан, Балык Бистәсенең Котлы Бөкәш, Биектау, Таулар җирлекләрендә вакцина ясатучылар саны күп түгел икән. Район дагы 30 кешелек бүлектә бер генә дә буш урын юк. Хәер, бу хәл бер Балык Бистәсендә генә түгел...

Барысы да – җавапсызлык бәһасе. Шунысы гына шомландыра: әле дәваларлык табиблар бар. Тик алар да тимер түгел. Кыл өстендә торган гомерләрне дә шул ук кыл өстендә торган табиблар коткара югыйсә...

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ГРИФ ХӘЙРУЛЛИН:

«МИН ТАТАР ИКӘН, НИЧЕК ИТЕП БҮТӘН ХАЛЫК БУЛЫЙМ ИНДЕ?»

Күптән түгел булып узган Милләт җыенында һәр татарны уйланырга мәҗбүр иткән чыгыш, мөгаен, Казахстаннан килгән татар галиме, «Туран» университеты профессоры, Казахстанның Татар-башкорт конгрессы рәисе урынбасары Гриф Тимерзаһит улы Хәйруллинныкы булгандыр. Милләттәшләребезнең саны ни өчен кими? Бердәмлекне саклап калу өчен ниләр эшләргә кирәк? Җанисәп вакытында без ни өчен татар дип язылырга тиеш? Татарлар: кичә, бүген, иртәгә... Шушы сорауларга җавап бирү йөзеннән ул кыска гына нотыгында әнә күпме чорны колачларга тырышты, татарның әчке проблемаларын хәл итәргә чакырды. Аның һәр сүзе татарны уятуга, уйландыруга юнәлдерелгән иде. Шул җәһәттән милләттәшебез белән тагын бер кат элемтәгә кереп, фикерләрен укучыларыбызга да җиткерергә булдык.

«Татар-информ»

:: Гриф Тимерзаһитович, татарлар ни өчен кимүгә таба бара?

– Бу мәсьәлә Татарстанның үзендә дә бик җитди тора. Читтәге татарлар турында инде әйтәсе дә юк. Үземә төрле җирләрдә, республикаларда яшәргә туры килде. Шуңа күрә бу проблеманы тирәнрәк аңлыймдыр. Минемчә, башка халыклар арасында яшәгән милләттәшләребез татарлыкларын саклап калу өчен күбрәк көч куя. Татарстанда исә үзләренең эреп, югалып барганнарын бик күпләр аңламый кебек тоела миңа. Нәтиҗәдә акрын гына урыслаша барабыз. Моны бер яктан аңларга да була, әлбәттә. Без 500 ел буена урыслар арасында яшибез. Шуңа ияләшкәнбез, катнаш никахлар төзибез, балаларның урысча сөйләшүенә табигый хәл итеп карыйбыз. Боларның барысы да милләтебезне кимүгә китерә. Дөрес, эшләнгән эшләр дә күп. Үз телевидениебез, газета-журналларыбыз, тапшыруларыбыз бар. Әмма алар белән генә әллә ни үзгәреш сизелми. Төрле чараларда, телевидениедә без күбрәк җыр-биюләргә игътибар бирәбез. Шуңа карамастан, яшьләребез Көнбатыш музыкасына тартыла. Димәк, татар сәнгатен үстерүгә дә күп көч куярга кирәк әле. Җырлап, биеп кенә дә яшәп булмый. Җитдирәк проблемалар белән шөгыльләнү таләп ителә.

:: Мәсәлән?

– Бу җәһәттән мин Татарстанның мөмкинлекләре бар дип уйлыйм. Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов та зур көч куя. Рәхмәтебез зур аңа. Барган җиреңдә татар диаспорасы белән очрашмый калганы юк. Бу читтә яшәүче татарлар өчен бик мөһим, башка халыклар арасында аларның абруйлары бермә-бер күтәрелә. Минемчә, проблеманы хәл итүнең төп юлы – татарның хокукын торгызу, булганнарын саклап калу. Сүз дә юк, беренче чиратта телне саклап калырга кирәк. Милли уку йортларының булмавы халыкны зәгыйфьләнккә илтә. Милли белем бирү системасын торгыза алмасак, халыкның миллилеген саклавы бик икеле.

:: Җанисәп барышында татарларның бүленү очраклары күп...

– Җанисәп вакытында һәркемнең өч юнәлешкә хокукы бар: билгеләнгән, танылган яки электән күрсәтелгән милләтне язу; шул милләтнең өлеше булган халык исемен язу; бөтенләй башка милләт исемен алу. Соңгысына килгәндә исә, теләсә кайсы телне туган телем дип тану хокукы (ялгышмасам, Россиядә бу мәсьәлә хәл ителгән) башка чит милләтләрне түгел, нәкъ менә рус милләте булып язылу мөмкинлеген күздә тотадыр. Әлбәттә, сез үзегезне алеут дип, японка, индианка, француженка дип тә яздыра аласыз. Тик барыбер бу фикердән баш тартачаксыз. Башка вариантларга килгәндә, мәсәлән, мин үземне мишәр дип яза алам, нәселем – мишәрләрдән. Әмма мин бу адымга бармаячакмын, чөнки заманында без телдә дә, сәнгатьтә дә һәм башка өлкәләрдә дә татар икәнлегебезне тоеп яшәдек. Дөрес, мишәр дип әйтүләре дә мөмкин иде, ләкин ул татарлыгыңны инкяр итү түгел, ә тамырыңны ачыклау гына булды.

> Ничек инде мишәр, керәшен, типтәр бүтән халык булсын ди? Башка бер олы халык та, динена яки тамырына карап, зур халыкны вакламый лабаса! Алар бездән акыллырактыр, күрәсең... Шулай итеп, бер генә юл кала: татар булып тусаң, татар булып языл.

Форсаттан файдаланып, тагын бер нәрсәгә тукталыйк әле. Һәр заманның үз кыйммәтләре, идеаллары, омтылышы буладыр. Бәлки, ялгышамдыр да, ләкин, миңа калса, хәзерге яшьләр күбрәк файда турында уйлый. Менә шушы яктан карaганда да, үз милләтең кешесе булу җайлырак. Әгәр милләтеңнең бер кисәкчеген милләт дип аерып, шунда язылсаң, синең халкың бәп-бәләкәй булып кала. Анда син кемгә кирәк, үзеңне сансызлату гына бит бу. Башка халыкка кушылсаң, син анда барыбер «ак карга», берәү дә сиңа тулысынча шул милләт кешесе итеп карамаячак. Өлкән буын кешесенең тәрбиясе башкачарак, әлбәттә. Милләтне үзгәртү фикере бер акылсызлык булып тоела. Мин татар икән, ничек итеп бүтән халык булыйм инде?

:: Милләтебезне, телебезне саклап калу өчен бүген безгә ниләр эшләргә?

– Һәрхәлдә, беренче чиратта үзебезгә кагылган якларны карарга кирәк: ничек халык санын арттырырга, ничек итеп аның бөтенлеген сакларга һәм ныгытырга («Бүлгәлә һәм хакимлек ит!» дигән хәрәкәткә юл куймаска), татар белән татар арасындагы аерымлыкларны эзләп, чокчынып тормаска (мондый аерымлыклар башка халыкларның төркемнәре арасында да әллә нихәтле). Читтә яшәүче татарларга юл ачу ысулларын табу зарур. Аларның күченеп килү, Татарстанда урнашу мәсьәләсе дә, читтәге татар яшьләрен мөмкин кадәр күбрәк мондагы уку йортларына җәлеп итүне дә әйтергә була. Кызганыч, безнең якта Татарстанга күчеп, аннан кире кайтучылар да, кайбер сәбәпләр аркасында укуга кабул ителмәгәннәр дә очрый. Гафу итегез, бәлки, мин ялгышамдыр да, әмма кайчакта, Татарстандагы татарлар үз милләтен бөтенләй югалту уе белән килешкәнме әллә, шуның өчен читтәге татарларга башка күз белән карыймы икән, дип уйга каласың.

Әлбәттә инде, иң мөһиме – татарларның милли үзаңын ныгыту өстендә эшләү. Моның өчен халкыңның тарихын, нәкъ менә үз галимнәрең тикшергән, ачкан, язган тарихны белергә кирәк. Үткәннәрен югалткан халык тиз арада үзе дә юкка чыга, көтү хәлендә кала. Бу фикер күптән һәм күпләргә билгеле бит. Халкыбызны гел канкойгыч, вәхши, кыргый итеп кенә тасвирлауга ышанасы да юк. Бер халык та күктән иңмәгән ләбаса, барысы да тарихи үсеш юлын үткән. Һәр халыкның яхшы якларын да, кимчелекләрен дә табарга була. Тарихыбызда бихисап акыл ияләре, галимнәр, шагыйрьләр булган һәм бар, безнең белән бөек ханнар җитәкчелек иткән, батырларыбыз дөнья тулы. Балаларга шуны аңлаталарны, татар беләме соң моны? Урамга чыгып сорап карагыз әле: күпме татарны санап бирерләр икән? Кубесе Габдулла Тукайны, Муса Җәлилне атар. Ә башкалар кайда? Телевидениедә тарихка, бөек шәхесләребезгә багышланган тапшыруларны бармак белән генә санарлык. Без пропаганданы шул тиклем генә алып барсак, кемне гаепләргә була?

Менә Милләт җыены узды, сүз дә юк, ул яхшы әзерләнгән, байтак вәкилләрне җыйнаган әһәмиятле бер чара булды. Шул чараны, аның эчтәлеген, анда булган хәлләрне барлык татарның да игътибарына җиткерә алдыкмы соң? Шушы уңышыбызны югары күтәреп, татарларның рухын күтәрә алдыкмы? Әллә матбугат моңа бер гадәти чара дип кенә карадымы? Югыйсә сөйләшү бик җитди булды бит, милли киемнәр дә, җыр-бию дә, мактану да күренмәде.

> Мактану дигәннән, әгәр без үзебезнең борынгы бөеклегебез белән мактанып кына йоклап ятсак, эш хәтәр. Милли рухны һәм үзаңны үстерү ул шапырынуга әйләнеп калырга тиеш түгел. Элеккеге уңышларны искә алып, бүгенге хәлебезне югары күтәреп, татар халкына, үзебезгә ихтирамны кирәкле дәрәҗәгә куярга кирәк, нигезле ихтирам үстерү кирәк бүген!

:: Чит төбәкләрдә яшәүче татарлар Татарстанга нинди өметләр баглый?

– Без, өметләнеп, нидер көтеп утырмаска, үзебез дә ярдәм итәргә тиешбез. Бердәмлек шунда чагыла да инде. Ә болай, үзебезгә килгәндә, Татарстан белән элемтәбез начар түгел. Заманында Семипалатинск шәһәрендә татар мәктәбенә Татарстан бик нык ярдәм итте. Дөрес, анда төрле милләт балалары укый, алар барысы да татар халык сәнгатенә катнашып китә. Татарлар бик таралып яши, бергә җыеп укытырга мөмкинлек юк, әлбәттә. Әмма без элеккедән калганча мәктәпне татар мәктәбе дип йөртәбез, шул дәрәҗәдә калдырырга омтылабыз да. Икътисад өлкәсендә дә зур эшләр эшләнә. Татарстан Казахстанга инвестицияләр кертә. Безнең мактанычыбыз – бу инвестицияләр кайбер башка илләрнекеннән дә күбрәк. Әмма, әйтергә кирәк, монда

сүз матди як турында гына бармый. Игътибар, теләктәшлек, милләттәшләр дигән җылы сүз – боларның барысы да күңелне күтәрә, эшләргә дәрт өсти. Әмма акчасыз булмый. Мәсәлән, якшәмбе мәктәбендә татар теле укытучысы тоту өчен аңа хезмәт хакы түләргә кирәк. 27 ел буе татар-рус телендә чыгып килүче «Фикер» газетасының мөхәррире булып эшләдем. Инде азрак ял итим дип уйлаган идем, алыштырырга кеше таба алмыйбыз. Хәзерге яшьләрнең бушка эшләп йөрисе килми бит.

Казахстанда 200 меңнән артыграк татар яши. Әйтергә кирәк, соңгы араларда сан ягыннан байтак кимедек. Туксанынчы елларда гына монда 340 мең татар исәпләнә иде. Дөрес, күбесе Россиягә, шул исәптән Татарстанга күченеп китте. Милләттәшләребезне катнаш никахлар да «йота». Бу очракта казахлашу турында әйтсәк, дөресрәк булыр. Кыргызстан, Үзбәкстан кебек Урта Азия республикаларында да шундый ук күренеш бара.

:: Хезмәтләрегез белән укучыларны да таныштырыйк әле.

– Моңа кадәр күп кенә китаплар, мәкаләләр басылган иде, алар арасында безнең милли проблемаларга багышланганнары да аз түгел. «Татар тарихы», «Казахстанда – татарлар» дип аталган китапларым бик популяр булды. Моннан ике ел элек «Без – татарлар», «Туфаниада» китаплары дөнья күрде. Поэзиям – «Дөнья бит ул», «Казанга – хат» җыентыкларында. Былтыр мин эшләгән университет «Идарә психологиясе» китабын бастырып чыгарды. Быел «Югары мәктәп педагогикасы» исемендәге лекцияләр курсы басыла. Ел ахырына кадәр татарча яңа шигырьләр китабы әзерләп ятам. Тагын бер китабымны Мәскәүдә бастырдым. Ул «Аралашу һәм үз-үзеңне тану» дип атала.

:: Сез гомер буена милләткә хезмәт итәсез, тарих төпкелендә актарынасыз. Ничек кенә булмасын, үткәннәр киләчәккә барып тоташа. Бу җәһәттән татарның киләчәк язмышын ничек күзаллыйсыз?

– Бик катлаулы сорау бу. Киләчәктәге язмышны ачык кына әйтеп булмыйдыр ул. Әлбәттә инде, читтәге факторлар белән беррәттән, күп нәрсә үзебезгә бәйле. Халкыбызны саклап кала алабызмы, әллә вакланып эреп бетәбезме – боларның барысы да беренче нәүбәттә үзебездән тора.

> Әгәр җебеп, йоклап ятсак, безне эретәчәкләр. Бу очракта үпкәләр урын да калмый. Үзебезне кулга алып, искиткеч бай тарихыбызга таянып, әллә нинди кыенлыклардан да исән чыга алган татар баласы булуыбызны онытмыйча, үҗәтләнеп алга барсак, туктамасак, алда безне күп гасырлы милләт гомере көтә.

Тарих битләрен актарсагыз, дөньяның һәрвакыт үзгәреп торганлыгын күрәсез. Хәтта бөек халык дигән дәрәҗә дә мәңгелек түгел. Бөекләр исемен латиняннар да, греклар да, төркиләр дә, гарәпләр дә (башка континентларда бүтәннәр дә) йөрткән. Ә бүген – башка хәл, өстәвенә шартларның, халыкларның, тормышларның үзгәрүе дә тизләште, көчәйде. Димәк, дөньяң үзгәрмәс, дип беркем дә гарантия бирә алмый. Мондый шартларда, тырышып-тырышып, бер булып укмашкан, берләшкән, бер бөтен хәлдә уртак телен, мәдәниятен, дини инануларын саклаган халык кына исән калырга сәләтле була дип уйлыйм мин. Кайчандыр АКШ галимнәре, постсовет дөньясында 2050 елда ике генә тел (рус теле һәм татар теле) кала, дип фаразлаган иде. Кем белә?

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ФЕРМЕР БУЛАТ ДУНАЕВ:

«ЯШЕЛЧӘЧЕЛЕК ТАРМАГЫНДА КУЛ ХЕЗМӘТЕ АЛДАН ЙӨРИ»

Кукмара районының Янил авылында яшәүче әтиле-уллы Булат һәм Камил Дунаевлар хуҗалыкларында үскән яшелчә уңышыннан бик канәгать быел. Без дә эшнең кызу чагына туры килдек. Дунаевлар, авыл халкы белән бергәләп, басуда кишер җыялар иде. Инде бәрәңге, сарымсак, суган, чөгендер уңышын җыеп алып, урнаштырырга да өлгергәннәр. Кишерне тапшыру белән дә проблемалары юк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Яшелчәчелек белән без дүрт ел элек шөгыльләнә башладык, – диде Булат Дунаев. – Башта Авыл хуҗалыгы министрлыгының грантын откан идек. Эшне шуның белән башлап җибәрдек. Орлыклар, ашламалар, акрынлап техника алдык. Ул елларда транспорт юнәтү авыррак иде. Танышлардан, дуслардан алып торган чаклар да булды. Хәзер эшне алып бару күпкә уңайлы.

Басуның күпчелек өлешендә кишер үсә. Быел фермерлар гектарыннан 300 центнер уңыш алуга ирешкән.

– Яшелчәчелекнең төп үзенчәлеге шунда: күпчелек эшне кул белән эшлисе. Урнаштыру проблемасы булганы юк. Быел ихтыяҗ тагын да зуррак, чөнки халыкта яшелчә уңмады, – ди алар.

Кишернең бер килограммын – 30, суганны – 30, сарымсакны – 250–300, бәрәңгене 25 сумнан сатканнар. Күпләр, коры ел килү сәбәпле, икенче икмәк уңышы азлыктан зарланса, Дунаевлар, киресенчә, уңыш мул булды, ди.

– 120 центнер бәрәңге алдык. Елына күрә бик яхшы булды. Гала сортын утырткан идек. Чәчәк аткан вакытта яңгыр явуның файдасы зур булды. Бәхет эше инде. Су сиптереп үстермәгәч, бар өмет – явым-төшемдә. Кишер дә эре, күп булды. Күрше-тирәдәге хуҗалыкларда бөтенләй тишелмәде бит. Кат-кат утыртып кына уңыш алучылар да булды. Безгә ул яктан уңыш елмайды. Тиз арада сатып та бетердек. Хәтта ярминкәләргә алып чыгарлык та калмады. Башка яшелчәләрне дә шулай тиз арада алып китеп бетерделәр, – диде Булат Дунаев.

Төп хезмәт әти белән ул җилкәсенә төшә. Бары тик сезон вакытында гына ярдәмгә авылдашларын дәшәләр.

– Чакыру белән үк, сөенә-сөенә киләбез. Акчаны вакытында түлиләр. Уңышлары да яхшы чыга. Без, авыл халкы, эштән курыкмыйбыз. Саулык булганда, тырышып эшлибез. Үзебезнең бакчадагы кишерләр болай уңмады. Башка авылдашлар да, яшелчә сорап, читкә бармый, үзебезнең егетләр янына килә, – диде үзен Илмира апа дип таныштырган авылдашы.

Яшелчәләрне, гадәттә, басудан гына алып китәләр икән. Без анда булган арада гына да берничә кеше кишер алып китте. Бәрәңге сораучы да булды, тик фермерлар анысын сатып бетергән инде.

– Тырышсаң, үз алдыңа максат куеп эшләсәң, авылда да менә дигән итеп яшәп була, – дигән фикердә тора Булат Дунаев. – Дөрес, иртә таңнан башлап кичкә кадәр эшләргә кирәк инде. Майның беренче көненнән үк басудан кайтып кермибез. Яшелчәләрне җыеп алгач та, туфракны әзерләп куярга кирәк. Ләкин тырышкан хезмәтнең нәтиҗәсен күргәч, дөрес юлда булуыбызга инанабыз һәм яңа максатлар куеп эшлибез.

Зөһрә САДЫЙКОВА

АКЧАНЫ ЯНГА КАЛДЫРА

ЮРИДИК ЗАТЛАР ӨЧЕН ШӘХСИ КАБИНЕТ УҢАЙЛЫКЛАРЫ

Эшмәкәрләр һәрвакыт «Вакыт – акча!» дигәнне истә тотып яши. «Татэнергосбыт» моны яхшы белә һәм шуңа күрә теләсә кайсы бизнес җитәкчеләренә, үзләренең офисларыннан чыкмыйча гына, счетлары буенча тиз генә түләү мөмкинлеген тәкъдим итә.

«Юридик затлар өчен шәхси кабинет» сервисы эшмәкәрләргә бик зур мөмкинлекләр ача. Аның ярдәмендә:

• онлайн режимда электр энергиясе өчен түләргә һәм исәпләгечнең күрсәткечләрен тапшырырга;

• үзегез өчен уңайлы вакытта компания белгеченең сезгә телефоннан шалтыратуына заказ бирергә яки аңа мөрәҗәгатегезне җибәрергә була: аның карап тикшерелүен дә Шәхси кабинетта күзәтеп торырга мөмкин;

• хисап чорында электр энергиясен куллану ведомостена (электрон почтага җибәрелә) заказ бирергә;

• түләүләр «тарихы»н барларга;

• энергетика өлкәсендә көн кадагына суга торган яңалыкларга язылырга һ.б. була.

«Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыятенең Шәхси кабинетыннан файдаланучыга әйләнү өчен безнең рәсми сайтта (tatenergosbyt.ru) теркәлү шарт. Моның өчен нибары өч юлны тутырырга: ИНН, ФИО һәм электр энергиясе белән тәэмин итү (сату-алу (тәэмин итү) килешүендә күрсәтелгән электрон почта адресын язып куярга кирәк.

Шунысын да әйтеп үтик: бүгенгә «Татэнергосбыт»ның 14 меңнән артыграк клиенты Шәхси кабинетның уңайлыкларын бәяләргә өлгерде инде. Сайтта теркәлеп, шәхси кабинет булдырган юридик затларның саны елдан-ел арта. Сервисның халыкка кирәклеген күрсәтүче дәлил булып тора бу.

«Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыятенең Шәхси кабинетында, офиска барып тормыйча гына, компаниянең барлык хезмәтләреннән файдалану мөмкинлеге тудырылу – клиентларның нәкъ менә безне сайлавына китерүче төп сәбәпләрнең берсе дә инде!

4 октябрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

05.00 «Җырлыйк әле!» 6+
05.50, 07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 12+
06.00 «Манзара» 6+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 23.00 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ» 12+
10.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Семь дней» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.50 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл баттл» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Халык моңнары» 6+
18.00 «Мин» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
23.50 «Черное озеро» Смертельный салют 16+
00.15 «Достояние республик» 12+
01.05 «ТЫЕЛГАН МӘХӘББӘТ» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 15.45, 01.05 «Манзара» 6+
08.05 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
09.00, 12.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
09.25, 03.00 «Әдәби хәзинә» 12+
10.00, 04.10 «Башваткыч» 12+
11.00, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.30, 00.15 «Тамчы-шоу» 6+
12.25, 18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.15 «Семь дней» 12+
14.30 «Аулак өй» 6+
15.15 «Ач, шигърият, серләреңне» 6+
19.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Новости Татарстана» 12+
21.25, 03.25 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт 6+
23.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
23.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами).
12.15 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское / Женское» 16+
17.00 «Время покажет» с Артемом Шейниным 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 «РУССКИЕ ГОРКИ» (S) 16+
23.35 «Вечерний Ургант» на Байконуре (S) 16+
00.15 «Познер» 16+
01.20, 03.05 «Время покажет» 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40, 18.40 «60 минут» 12+
14.55, 02.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ»
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.20 «ШУША» 16+
23.20 «Вечер с Владимиром Соловьевым» 12+
04.05 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 12.00, 14.10, 17.00, 01.55 Новости
06.05, 12.05, 15.15, 21.00, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.05, 12.45 Специальный репортаж 12+
09.25 «ГЕРОЙ» 12+
11.30 Борьба. Чемпионат мира. Трансляция из Норвегии 0+
13.05, 14.15 «КАРАТЕЛЬНЫЙ ОТРЯД» 16+
15.55, 17.05 «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ» 16+
18.10 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. Обзор тура 0+
18.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Астана» (Казахстан)
21.30 Смешанные единоборства. АСА. Абубакар Вагаев против Устармагомеда Гаджидаудова. Прямая трансляция из Грозного
00.25 Тотальный футбол 12+
00.55 Бокс. Bare Knuckle FC. Джонни Бедфорд против Реджи Барнетта. Трансляция из США 16+
02.00 «Человек из футбола» 12+
02.30 «Самые сильные. Сергей Чердынцев» 12+

НТВ

04.40 «ГЛАЗА В ГЛАЗА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» (S) 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.30 Сегодня
08.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.25 «За гранью» (S) 16+
17.30 «ДНК» (S) 16+
18.35, 19.40 «БАЛАБОЛ» (S) 16+
21.20 «МЕТОД МИХАЙЛОВА» (S) 16+
23.50 «КОНСУЛЬТАНТ» (S) 16+
03.30 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» (S) 16+
04.00 «МАЙОР СОКОЛОВ. ИГРА БЕЗ ПРАВИЛ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.15 «6 кадров» 16+
06.45 «Реальная мистика» «Добыча» 16+
07.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведемся!» 16+
09.50 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Пятно» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55 «АВАНТЮРА» 16+
19.00 «ХОРОШИЙ ПАРЕНЬ» 1-я – 4-я серии 16+
23.25 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 4» 9-я – 10-я серии 16+
01.30 «Реальная мистика» 16+
02.20 «Верну любимого» 16+
02.45 «Порча» 16+
03.10 «Знахарка» 16+
03.35 «Понять. Простить» 16+
04.35 «Тест на отцовство» 16+

ЗВЕЗДА

06.10 «Легенды госбезопасности. Бир и Халеф. Меч самурая» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 21.15 Новости дня
09.20 «МАКСИМ ПЕРЕПЕЛИЦА» 0+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.25 «Оружие Победы» 6+
13.45, 14.05 «МАРЬИНА РОЩА» 12+
14.00 Военные новости
18.30 «Специальный репортаж» 12+
18.50 «Военные трибуналы» «Краснодарский процесс» 12+
19.40 «Скрытые угрозы» «Альманах №73» 12+
20.25 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал 12+
23.05 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.40 «ПОЕЗД ВНЕ РАСПИСАНИЯ» 12+
01.20 «КОМАНДИР КОРАБЛЯ» 6+
03.00 «Су-34» 6+
03.40 «Сделано в СССР» 6+
03.50 «МАРЬИНА РОЩА» 1-я и 2-я серии 12+

5 октябрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

05.00 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
05.50, 07.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре 12+
06.00 «Манзара» 6+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 23.00 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ» 12+
10.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
11.00 «Туган җир» 12+
11.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Ком сәгате» 12+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Фолиант в столетнем переплете» 12+
14.50 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Ания Туишева җырлый» 6+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» (Казань) – «Динамо» (Минск). Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Семь дней+». Рахима Арсланова 12+
00.40 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
01.05 «ТЫЕЛГАН МӘХӘББӘТ» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 15.45, 01.05 «Манзара» 6+
08.05 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
09.00, 12.00, 15.00, 18.00, 21.30, 00.00 «Яңалыклар» 12+
09.25, 14.00, 23.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
10.00, 04.10 «Җырлыйк әле!» 6+
11.05, 17.30, 00.40 «Татарлар» 12+
11.30, 00.15 «Халкым минем» 12+
12.25, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.15 «Ачыктан-ачык». Виталий Агапов 12+
14.30 «Аулак өй» 6+
15.15 «Ач, шигърият, серләреңне» 6+
18.20 «Таяну ноктасы» 16+
19.00 Хоккей. КХЛ чемпионаты. «Ак барс» (Казан) – «Динамо» (Минск). Трансляция – Казаннан 6+
21.55, 03.25 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт 6+
23.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 «Вызов» Прямая трансляция с Байконура
09.00 Новости
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское / Женское» 16+
17.00 «Время покажет» с Артемом Шейниным 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 «РУССКИЕ ГОРКИ» 16+
23.35 «Вечерний Ургант» 16+
00.15 «Александр Михайлов» 12+
01.15, 03.05 «Время покажет» 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40, 18.40 «60 минут» 12+
14.55, 02.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ»
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.20 «ШУША» 16+
23.20 «Вечер с Владимиром Соловьевым» 12+
04.05 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.00, 17.00, 01.55 Новости
06.05, 12.05, 18.55, 21.50 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 12.50 Специальный репортаж 12+
09.20, 15.55, 17.05 «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ» 16+
11.30 Борьба. Чемпионат мира. Трансляция из Норвегии 0+
13.10 Все на регби! 12+
13.55 Регби. Чемпионат России. «Енисей-СТМ» (Красноярск) – ЦСКА. Прямая трансляция
18.10 Смешанные единоборства. Bellator. Кристиана «Сайборг» Жустино против Арлин Бленкоув. Трансляция из США 16+
19.25 Хоккей. КХЛ. СКА (Санкт-Петербург) – «Локомотив» (Ярославль). Прямая трансляция
22.50 «ЭКСТРЕМАЛЫ» 12+
00.45 Бокс. Bare Knuckle FC. Дакота Кокрейн против Майка Ричмена. Сэм Шумейкер против Джоша Бернса. Трансляция из США 16+
02.00 «Голевая неделя» 0+

НТВ

04.45 «ГЛАЗА В ГЛАЗА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» (S) 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.30 Сегодня
08.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.25 «За гранью» (S) 16+
17.30 «ДНК» (S) 16+
18.35, 19.40 «БАЛАБОЛ» (S) 16+
21.20 «МЕТОД МИХАЙЛОВА» (S) 16+
23.50 Детектив «КОНСУЛЬТАНТ» (S) 16+
03.35 Их нравы 0+
04.00 «МАЙОР СОКОЛОВ. ИГРА БЕЗ ПРАВИЛ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.20 «6 кадров» 16+
06.45 «Реальная мистика» «И прах сожжет тебя» 16+
07.45 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.50 «Давай разведемся!» 16+
09.55 «Тест на отцовство» 16+
12.05 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча» «Переплетенные» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «СОЛЕНАЯ КАРАМЕЛЬ» 16+
19.00 «ХОРОШИЙ ПАРЕНЬ» 5-я – 8-я серии 16+
23.25 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 4» 11-я – 12-я серии 16+
01.30 «Реальная мистика» 16+
02.25 «Верну любимого» 16+
02.50 «Порча» 16+
03.15 «Знахарка» 16+
03.40 «Понять. Простить» 16+
04.40 «Тест на отцовство» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «МАРЬИНА РОЩА» 3-я и 4-я серии 12+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 21.15 Новости дня
09.30 «Сделано в СССР». Док. сериал
09.40, 01.30 «ЖИВИТЕ В РАДОСТИ» 6+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 2+
13.25 «Оружие Победы». Док. сериал 6+
13.45, 14.05 «МАРЬИНА РОЩА» 5-я – 8-я серии 12+
14.00 Военные новости
18.30 «Специальный репортаж» 12+
18.50 «Военные трибуналы». «Харьковский процесс» 12+
19.40 «Легенды армии». Василий Минаков. 12+
20.25 «Улика из прошлого» 16+
23.05 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.40 «МАКСИМ ПЕРЕПЕЛИЦА» 0+
02.45 «Ан-2» 6+
03.25 «Вспоминая блокадный Ленинград». Док. фильм 12+
03.50 «МАРЬИНА РОЩА» 5-я и 6-я серии 12+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 4–10 ОКТЯБРЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04) Төрле вакыйгалар, очрашулар һәм яңа танышулар Кучкарларны илһамландырачак. Атна уртасында карьера үсеше фаразлана. Уңыш елмайганда, барлык мөмкинлекләрдән файдаланып калырга ашыгыгыз.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05) Тормышыгызның төрле өлкәләрендә үзгәреш җилләре исә. Йолдызлар сезгә көтелмәгән очрашулар һәм күңелле яңалыклар вәгъдә итә. Билгеле бер максатыгыз бар икән, аннан читкә тайпылмасагыз хәерле. Эшегездә нидер сез теләгәнчә бармый икән, артык хафаланмагыз. Бар да вакытлыча.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06) Эш урынында артык кире булмагыз. Бу сыйфатыгыз сезне бер дә бизәми. Йолдызлар бу атнада сезне төрле вак-төяк мәшәкатьләр урап узачак дип вәгъдә бирә. Ялларга билгеләп куйган планнарыгыз бар икән, аларны үзгәртмәгез.

КЫСЛА (22.06 – 22.07) Гайбәт, имеш-мимешкә ышанып чакмыни? Сезгә көнләшеп караган кешеләрдән ерактарак торыгыз. Бу атнада сезгә уңыш елмаячак. Бәлки, нәрсәдер отарсыз, бәлки, кем беләндер танышырсыз..

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08) Бу атнаны гаилә, шәхси мәнфәгатьләрне кайгыртуга багышларга кирәк. Шулай ук ерак юлга чыгып, башны ял иттереп алу да зыянга булмас. Яхшы кәеф, яңа хисләр кирәк! Мәхәббәттә исә сак булыгыз. Өермәләргә кереп, башыгыз чуалуы ихтимал.

КЫЗ (24.08 – 22.09) Төшенкелеккә биреләсез түгелме? Моннан чыгу юлы – яңа һөнәр яисә яңа мәхәббәт. Кызыксынуларыгыз төрле якка авышып тора. Атна азагында Кызларның матди хәле яхшыруы ихтимал.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10) Атна башы бизнеска бәйле мөһим мәсьәләләрне хәл итү өчен уңайлы чор булыр. Җомга шулай ук яңа элемтәләр булдыру, эшлекле очрашулар уздыру өчен шәп вакыт. Якшәмбе күп итеп акча китерәчәк. Ялгызлар үзләренә пар эзли башлаячак.

ЧАЯН (24.10 – 22.11) Хыялый һәм тыныч чорыгыз. Үзегезгә ошамаган, җеннәрегез туры килмәгән кешеләр белән очрашмавыгыз хәерле. Һөнәри сорауларга килгәндә, йөрәгегезне тыңлагыз. Гаиләгез дә сезнең игътибарга мохтаҗ.

УКЧЫ (23.11 – 21.12) Теләсә кемгә вәгъдәләр биреп йөрмәгез. Аларны үти алмавыгыз да бар бит. Яңа эш урыны турында хыялланасыз. Бу атнада эзли башларга мөмкин. Ял көннәрен яраткан кешеләрегез янәшәсендә үткәрү әйбәт булыр.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01) Бу атнагыз өйдәге мәшәкатьләргә багышланачак. Сезнең ярдәмне көтеп торган күпме кеше бар икән бит! Шулай ук үпкә-рәнҗешләргә урын калдырмаска кирәш итегә. Күңелегезне күптән тырнап торган вакыйгаларны әчегезгә җыймагыз.

СУКОЯР (21.01 – 19.02) Атна башында җитәкчелек белән сүзгә килүегез ихтимал. Ялгыша күрмәгез! Ял көннәрегез истә калырлык булып узар. Мәхәббәт турында да онытмасагыз иде. Ялгызларны бер яхшы кешегә димләргә мөмкиннәр.

БАЛЫК (20.02 – 20.03) Уйланылмаган гамәлләр чоры түгел. Бу атнада сезнең төп кагыйдә – ашыкмау. Эш урынында вакытлыча мәшәкатьләр килеп тумагае. Әммә оптимизм рухын югалтмагыз.

Белдерү

ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ ПО СОГЛАСОВАНИЮ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА

Кадастровым инженером Осиповым Алексеем Федоровичем (г. Казань, ул. Журналистов, д. 30, кв. 108, e-mail: geodezy@rambler.ru, тел.: +7 9600559524, СНИЛС 047-159-072-63, квалификационный аттестат 16-15-843; реестр кадастровых инженеров № 36006; СРО АКИ «Поволжье» № 1145 протокол № 18/2016 от 22.11.2016 г) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:16:214101:14, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, некоммерческое садоводческое товарищество «Солонка», участок 14 выполняются кадастровые работы по уточнению местоположения границы земельного участка. Заказчиком кадастровых работ является Вилкова Юлия Владимировна, адрес: 420095, Российская Федерация, Республика Татарстан (Татарстан), г. Казань, ул. Шамиля Усманова, д. 29, кв. 50, тел.: +7 9503245705. Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, некоммерческое садоводческое товарищество «Солонка», участок 14, 31 октября 2021 г. в 10 часов 00 минут. С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: г. Казань, ул. Журналистов, д. 30, кв. 108, e-mail: geodezy@rambler.ru, тел.: +7 9600559524. Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана, и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 1 октября 2021 г. по 31 октября 2021 г. по адресу: г. Казань, ул. Журналистов, д. 30, кв. 108, e-mail: geodezy@rambler.ru, тел.: +7 9600559524. Смежный земельный участок, с правообладателями которого требуется согласовать местоположение границ: 16:16:214101:1022, расположенный по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, некоммерческое садоводческое товарищество «Солонка», участок 13.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 г. № 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

ГАСТРИТТАН КЕСӘЛ БУЛЫША

Күз – хроник авырулардан интеккән кешеләр өчен зур сынау чоры. Ашказаны-эчәк авырулары, аерым алганда, гастрит белән ашказаны җәрәхәте (язва) булган кешеләр бу чорда аеруча тилмерә.

Табиб-гастроэнтеролог Индира ГЫЙМАЛТДИНОВА сорауларга ачыклык кертте.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Индира Мөнировна, күзен бик күп хроник авырулар, бигрәк тә гастрит, язва баш калкыта. Бу күренеш нәрсә белән аңлатыла?

– Моның берничә сәбәбе бар. Беренчедән, һава торышы кисәк үзгәреп тору сәбәпле, кешенең иммунитеты какшый. Ашказаны-эчәк тракты сүлпәнрәк эшли башлый. Организм витаминнарга кытлык кичерә башлый. Күз көне еш күзәтелә торган депрессия, стресслар да гастритның баш калкытуына сәбәпче була.

:: Гастрит белән ашказаны җәрәхәте бер-берсеннән нинди билгеләр белән аерыла?

– Гастрит белән язваның билгеләре охшаш диярлек. Аерма бары шунда: гастрит вакытында ашаганнан соң 3–4 сәгать үткәч, эч авыртырга тотына. Язва вакытында исә ашаганнан соң ук яки берничә сәгать үткәч авырта башлый. Гастрит – шактый киң таралган авыру. Аннан күбрәк шәһәр халкы интегә. Гастрит вакытында ашказанында авырлык сизелә, чәнчү, кикерү, күңел болгану кебек билгеләр күзәтелә. Катлаулырак очракта кеше косарга да мөмкин. Язва вакытында, гадәттә, күңел болгана, сару кайный. Косканнан соң кешенең хәле җиңеләя төшә. Гастриттан аермалы буларак, язва вакытында кешенең тәнлә дә ашказаны авырта. Соңгы арада язва берниндн билгеләрсез генә дә уза башлады. Шуңа күрә ашказанын төгәл кайсы чир борчыганын белү өчен, ФГДС узарга кирәк. Бу билгеләрнең берсе генә күзәтелсә дә, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Үзлегеңнән генә дәваланырга тырышу – зур хата.

:: Әлеге чирләрне халык медицинасы ярдәмендә дәвалауга ничек карыйсыз?

– Язва белән гастритны ниндидер үләннәр, майлар ярдәмендә генә дәваларга маташучылар да очрый. Әмма ашказаны-эчәк авыруларыннан алай гына котылам димә. Андый ысуллар ярдәмендә чирне, киресенчә, азындырырга гына мөмкин. Ашказаны җәрәхәте белән гастритның бик катлаулы формасы булмаса, кеше өйдә генә дәвалана ала. Моның өчен, иң беренче чиратта, табиб язып биргән даруларны эчәргә, махсус диета тотарга, сәламәт тормыш алып барырга, тәмәке тарту, спиртлы эчемлекләр куллану кебек начар гадәтләрдән баш тартырга кирәк. Әлеге чирләрдән кесәл дә бик шәп булыша.

:: Гастрит яки язва баш калкыткан чорда ничек тукланырга кирәк?

– Беренче билгеләре күренә башлауга, рационга үт суы бүленеп чыгуны көчәйтүче ризыкларны кертмәгез. Бу исемлеккә тозлы, кыздырылган, ачы, ысланган ашамлык, төрле соус, тәмләткечләр, әче җиләк-җимеш керә. Гастриттан интеккән кешеләргә газлы су, камыр ризыклары, торт һәм кремлы пирожныйлардан да баш тартырга туры киләчәк. Чир баш калкыткан чорда ризыкны һәр өч сәгать саен аз-азлап ашарга кирәк. Тәнгә каршы йогырт, кесәл эчеп куйсагыз да, комачауламас. Ашказанының лайлалы тышчасы ялкынсынмасын өчен, ризыкны җылы килеш ашарга кирәк.

Киңәш-табыш

Кан басымы югары булганда

Вак итеп туралган 1 чәй кашыгы әремне 400 мл кайнап кына чыккан суда 20 минут тәнәтергә. Тәменчә бал өстәп, көнгә өч мәртәбә, ашарга 30 минут кала, ¼ стакан күләмендә эчәргә кирәк.

Кара миләш – геморройдан дәва

Көзге нигъмәт – кара миләш составында капиллярларны ныгытучы Р витамины бар. Ул анда кара карлыганга караганда 2 тапкыр күбрәк. Кара миләш җимешләрендә йод та күп. Организмы витаминнарга кытлык кичергән, бөерендә таш булган, гипертония, циститтан интеккән кешеләргә дә кара миләш ашарга киңәш ителә. Гипертоник авыруны һәм атеросклерозны дәвалау өчен 1 кг кара миләшне 700 г шикәр комы кушып изәргә кирәк. Шуны көненә ике мәртәбә 75–100әр г ашарга киңәш ителә. Геморрой вакытында бер үк күләмдә алынган кара миләш белән балны кайнаталар һәм көненә 3 мәртәбә ашарга 30 минут кала 100 әр г кабалар.

Дәфнә яфрагы буыннарны чистарта

Зурлыгына карап, 3–5 дәфнә (лавр) яфрагын 300 мл суга салып, 5 минут кайнатырга кирәк. Кайтканда савытның капкачын ябасы түгел. Аннан шуны 4–5 сәгатькә төреп куярга яки термоста тәнәтергә кирәк. Тәнәтмәне 12 сәгать буе аз-азлап эчәсе. 3 көн эчкәч, бер атна тәнәфес ясарга һәм дәвалану курсын тагын кабатларга кирәк. Бу көннәрдә ит ашамый торырга киңәш ителә. Лавр яфрагы тәнәтмәсе буыннарны чистарта, тозларны чыгара.

Белмәсәң бел!

Бәйләү тынычландыра

Аз гына борчуыгыз булса, бәйләргә утырыгыз! Америка галимнәре атнага өч тапкыр кул эше белән шөгыльләнгән кешенең күңеле тынычлана, киеренкелек кими дип ышандыра. Бәйләү баш миенә йога кебек тәэсир итә. Неврологиядә бәйләүне «яңа йога» дип атыйлар. Бәйләү игътибарны арттыра, бәйләгән вакытта кешенең баш мие тулысы белән эшли, бәхет гормоннары бүленеп чыга. Бәйләүче кешенең психик халәте яхшыра, иҗади мөмкинлекләре арта, хәтере яхшыра дип ышандыра белгечләр. Галимнәр бәйләү белән мавыккан өлкән яшьтәге кешенең акылы камил калуын, аларның озаграк та яшәвен ачыклаган.

Сәламәтлек киемнән башлана



Кеше сәламәтлегенә аның ни белән туклануы, нинди тормыш рәвеше алып баруы гына түгел, кигән киеме дә йогынты ясый. Хатын-кызларга бу уңайдан аеруча игътибарлы булырга киңәш итә белгечләр. Ник дигәндә, матурлык артыннан куып киелгән киемнәрнең күпчелеге сәламәтлек өчен зыянлы, ди алар.

СЫЛАНЫП ТОРГАН ЭЧКЕ КИЕМ

Ябык күренер өчен кысып тора торган эчке киемнәр киярга яратучыларга да сак булырга кирәк. Хатын-кыз гардеробындагы мондый эчке киемнәр ашкайнату системасында тайпылышлар китереп чыгарырга, кече оча сөяге тирәсендә кан әйләнешен бозарга мөмкин.

ДЖИНСЫ-СКИННИ

Хатын-кыз өчен иң зыянлы кием шушы! Хәзер бик модада булган skinny моделен бик яратсагыз да, аңардан баш тарту хәерлерәк булыр. Гел мондый джинсыдан йөрисез икән, тән кызару, эч күбү һәм кече оча сөяге әгъзаларындагы веналарда кан йөреше бозылуга әзер булыгыз. Яшүсмер чорда бик тар чалбар кию оча сөягенең тараюына һәм кысрылыкка китерергә мөмкин. Эштә көн буе утырып эшлисез икән, тыгыз тукымалы джинсы чалбар кан әйләнешен бозарга мөмкин.

ТИГЕЗ ТАБАНЛЫ АЯК КИЕМЕ

Биек үкчә генә аякка зыян сала дип уйласагыз, ялгышасыз – тигез табанлы аяк киемен гел кию дә шактый проблемалар китереп чыгарырга мөмкин. Ир-атларныкы кебек ботинка киярга яратасыз икән, моның нәтиҗәсе буыннар сызлавы булып килеп чыгу ихтималын онытмагыз. Бөтен нәрсәдәге кебек монда да алтын урталык кирәк. Үзегезне башка төрле аяк киеменнән күрергә теләмәсәгез дә, кайчакларда аз гына үкчәсе булган аяк киеменнән дә йөргәләгез.

pixabay.com

АВЫР СУМКА

«Хатын-кызга авыр күтәрергә ярамый» дигән сүзне еш ишетәбез. Әмма теләсәк-теләмәсәк тә, кайчак күтәрергә туры килә шул. Иңбашына аскан авыр сумка гәүдә торышын боза, ардырта һәм, гомумән, читтән караганда бер дә матур күренми. Сумка белән гел авыр әйбер ташырга мәҗбүрсез икән, һич югы иңбашына аса торган ул зур авыр сумканы быелгы сезонда модада булган рюкзакка алыштырыгыз.

БИЕК ҮКЧӘЛЕ АЯК КИЕМЕ

Биек үкчәле туфли еш кына буыннар сызлавы, умыртка баганасында бүсер чыгу кебек шактый катлаулы чирләрнең сәбәпчесе була. Шуңа күрә биек үкчәле туфлины мөмкин кадәр сирәгрәк киярга кирәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Киңәш

ЛАМИНАТ САЙЛАУ СЕРЛӘРЕ

Бакча эшләре тәмамланганнан соң, күптән кичектерелеп йөргән ремонт эшләренә керешер өчен көз – менә дигән вакыт. Эшне идәннән башласак, төзелеш кирәк-яраклары сату кибете консультанты Марат ИБРАҺИМОВ, ламинат сайлау өчен кибеткә барганчы аның турында гап-гади генә нәрсәләрне белеп тору яхшы булыр, ди.



1 «Зарарсыз ламинат буламы?» дигән сорау бирүчеләр еш очрый. Әлеге сорауга җавап табу өчен аның нәрсәдән эшләнгәненә игътибар итик. Ламинатның 90 проценты прессланган агач материалларыннан тора. Өске катламы – меламин сумаласы белән туендырылган крафт кәгазе. Нәкъ менә шул катлам ламинатның күпме хезмәт итәчәге өчен җавап бирә. Әмма ул сыйфат турында сөйләшкәндә иң мөһиме булып саналмый. Гадәттә фатир, йорт өчен ламинатны 32 һәм 33 нче класслылар арасыннан сайларга кушалар. Монда сүз нәкъ менә әлеге өске катлам турында бара. 33 нче классның өске катламы берничә тапкыр калынрак була. Аш бүлмәсе, коридор өчен югарырак класслы, ә йокы бүлмәләре өчен түбән класслы ламинат сайларга киңәш ителә.

2 Ламинатның икенче катламы – бизәкләр төшерелгән катлам. Хәтта кыйммәтле ламинатлар җитештерүчеләрнең дә бер үк рәсем 8–10 панельдә кабатланырга мөмкин. Ә ул сирәгрәк кабатланган саен яхшырак санала.

3 Ламинатның өченче – урта катламы нык итеп прессланган агач өлеше. Әлеге катламның нык прессланган булуы аның дымга чыдамлылыгы, беркетүче «йозак»ларының никадәр нык булуы, бәрелүгә каршы торучанлыгы, салкын һәм җылы үткәрүчәнлеге, тавыш изоляциясе өчен җавап бирә. Ламинатның бер кимчелеге бар: ул тавышны дүрт тапкырга кадәр арттыра. Аның әлеге катламы ныграк булган саен ул җылы, салкын һәм тавышны ныграк үткәрә.

4 Ламинатның соңгы – дүртенче катламы меламин белән туендырылган крафт кәгазеннән тора. Температура үзгәргәндә ламинатның формасы югалмасын һәм «йозак»лары «уйнамасын» өчен нәкъ менә әлеге катлам җавап бирә. Очсызлы ламинат җитештерүчеләр әлеге катламны юка итеп эшли. Шунлыктан ламинатның тора-бара бер-берсе белән тоташтырылган җирләрендә кытыршылыклар барлыкка килергә, формасы югалырга, күпереп чыгарга мөмкин.

Исеңдә тот!

✓ Теләсә нинди ламинат алып җәйгәнче, башта аны өйрәнегез. Чөнки сыйфатлы ламинатны, бердән, үзегез дә җәя алачаксыз, икенчедән, ул 7–10 елга озаграк хезмәт итәчәк.

✓ Ламинатның Европада җитештерелгәннәрен сайласагыз, отмассыз. Чөнки алар сыйфаты буенча яхшырак, зарарсыз һәм озаграк хезмәт итә. Кытайда җитештерелгән ламинатларның сыйфаты күпкә түбән.

✓ Ламинатны нык юешләп юарга ярамый, диләр. Ә чынлыкта, яхшысын юешләп юарга ярый.

✓ «Ламинатмы әллә линолеуммы?» – дип сораучылар да еш очрый. Хәзерге кайбер линолеумнар җәйгәннән соң нәкъ ламинат төсле күренә. Әлбәттә, аны җәю күпкә җайлырак. Сыйфатлы линолеум белән сыйфатлы ламинатның бәясе бер чама.

ЧЕЛТӘР АГАРТАБЫЗ

Хуҗабикәләрнең тәрәзәләр, челтәрпәрдәләрне юып элә торган вакыты. Шуны истә тотып, саргайган челтәрне агартуның берничә ысулын тәкъдим итәбез.

Тоз. Челтәрне тоз һәм кер порошогы эремәсенә (1 литр суга 1әр чәй кашыгы исәбеннән) салып, 4–8 сәгать тотарга. Шуннан соң машинада «деликатный режим»га куеп юарга һәм тоз эремәсендә чайкап алырга.

Крахмал. Челтәрне гадәттәгечә юганнан соң бәрәңге крахмалы эремәсендә (2 литр кайнар суга 1 аш кашыгы исәбеннән) 2–6 сәгать тотарга. Шуннан, чайкамыйча һәм сыкмыйча гына, элеп киптерергә.

Перекись һәм нашатырь. Салкын суга нашатырь спирты (3 литр суга 1 чәй кашыгы) һәм 3 процентлы водород перекисе (3 литр суга 1 аш кашыгы) салып болгатырга. Челтәрне югач, шушы эремәгә салырга. Ярты сәгать узгач, чайкарга.

Тәмле булсын!

Кишерле балан бәлеше

Тәскирә ВӘГЫЙЗОВА рецепты

Кирәк: 1 кап маргарин, 1 стакан шикәр комы, 1 кап камыр көпшәкләндергеч, 3 стакан чамасы он, пешкән балан һәм бер кишер.

Маргаринны угычтан уып, шуңа шикәр комы, камыр көпшәкләндергеч салабыз да кул белән уабыз. Ярты стакан сөт өстәп, камыр басабыз һәм майлы табага җәябез. Пешкән баланны изеп, вак тишекле угычтан кишер уып салабыз. Камыр өстенә эчлекне салып, бәлеш ясыйбыз һәм 180 градуска җылытылган газ мичендә 20 минут чамасы пешерәбез.

Белеп тор!

ТЕЛЕФОНЫҢ ОЗАК ЭШЛӘСЕН, ДИСӘҢ

Телефонга тиз арада зарядка җыйдырырга кирәк булганда, нишләргә? Хәер, заманча телефоннарның кайберләрендә болай да «тиз зарядка» функциясе бар анысы. Булмаса, нишләргә?

▶ «Полет» режимын кабызырга. Теләсә кайсы элемтәне (мобиль элемтә, Wi-Fi һәм Bluetooth) тулысынча өзә ул. Челтәрдән аергач, зарядка бик тиз җыела. Хәтта телефон өстәлдә тик кенә ятканда да, челтәрдән аермаган очракта, зарядка кими.

▶ Тышлыгын салдырырга. Заманча телефоннарның аккумуляторлары җылынудан «курка». Телефон артык җылына башласа, озак «уйлый» башлый. Шулай ук зарядка җыюга да кагыла бу – җылынса, телефон әкренрәк «кыймылдый». Шуңа күрә, тиз кирәк булганда, тышлыгын салдырып зарядкага кую әйбәт.

ВИТАМИНЛЫ КӨЗГЕ БИТЛЕКЛӘР

Кәбестәдән

Мондый битлек тән тиресен агарта, дымландыра. Ак кучәнле кәбестәнең ике яфрагын юка гына итеп озынча турап, сөткә салабыз һәм куе ботка хәленә килгәнче пешерәбез. 1әр чәй кашыгы зәйтүн мае һәм лимон согы өстибез. Болгатабыз. Катнашманы марля аша сөзеп, суын сыгабыз. Бит-муенга сылагач, 10 минут тотабыз һәм җылы су белән юып төшерәбез.

Сырганактан

Аннан ясалган битлек бит һәм муен тиресен яшәртеп, шомартып җибәрә. Моның өчен 1 аш кашыгы эремчек, 1 аш кашыгы каймак һәм 1 аш кашыгы сырганак согы кирәк. Барысын бергә болгатып, биткә һәм муенга сылыйбыз да 20 минут тотабыз. Шуннан соң җылы су белән юып төшерәбез.

Кызыл миләштән

Тән тиресен тынычландыра, ялкынсынуга каршы көрәшә торган битлек бу. Миләшне сытып, ботка хәленә китерәбез, шуңа бераз бал өстәп, биткә һәм муенга сылыйбыз. 15 минуттан җылы су белән юып төшерәбез.

Сихәт

Иммунитетны ныгыта торган эчемлек

Балан сезонында иммунитетны ныгытуга ярдәм итә торган бик тәмле «дару» ясамыйча калмагыз!

Бакчагыздан балан җыегыз, кибеттән бер гранат сатып алыгыз. Ярты литрлы пыяла банканы парландырып чистартып алыгыз. Бер кулъмдәге балан белән гранат бөртекләрен банкага тутыртып, өстен каплагыз. Банканы тастымалга төреп, суыткычка куегыз.

1 аш кашыгы катнашмага ярты стакан кайнаган су салып, 40–50 минут төнәтегез. Сихәтле эчемлекне, ашаганчы, көненә 1–3 тапкыр ясап эчегез.

Бакчачы почмагы

Роза куаклары әле һаман чәчәктә утыра. Аларны кайчан һәм ничек кисәргә?

Гөлия ГАЛИУЛЛИНА.
Балык Бистәсе

Эльмира ИСХАКОВА җавап бирә:

– Кырау сугып, җирләр катырганч кисәбез. Әйбәтрәк 3–4 ботагын калдырып, астан 4–5 бөре санап кисәбез. Актык бөре эчкә таба үсеп китә торган булмасын. Ә тышкы якка таба үсә торганы калырга тиеш. Куакның уртасындагы карт, шулай ук зәгыйфь ботакларны төбеннән кисеп ташлыйбыз. Гомумән, куакны әйбәтләп сирәклибез. Барлык яфракларын да кисеп ташлыйбыз. Һава температурасы –5 градуска төшкәч, каплап куябыз.

Валентина СЕМЕНОВА әзерләде

АХЫРЗАМАННАН КАЧЫП БУЛМЫЙ

Еш кына: «Ахырзаман галәмәтедер бу!» – дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Чынлап та, хәзерге тормышыбыз шөкер итәрлек булса да, җәмгыятьтәге кайбер күренешләр кешеләрне сагаерга, уйланырга мәҗбүр итә. Ахырзаман җиткәнен ничек аңларга? Аның билгеле көне бармы? Кеше аңа ничек әзерләнергә тиеш?

dumrt.ru

Лаеш районындагы «Ихлас» мәчете имамы Мөдәррис ГЫЙМРАНОВ белән шушы сорауларга җавап эзләдек.

:: Хәзрәт, ахырзаманның зур һәм кече билгеләре бар дип беләм. Алар нәрсәсе белән аерыла?

– Кыямәт көне, ахырзаман, дибез. Аның атамалары күп. Кыямәт көне алдыннан ниләр буласы хакында Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә һәм рәсүлебез Мөхәммәд (с.г.в) хәдисләрендә бәйнә-бәйнә аңлаткан. Зур һәм кече (урта) галәмәтләре бар ахырзаманның. Зур галәмәтләр – ун. Кече һәм урта галәмәтләр арасындагы вакыт аралыгы билгесез. Кайбер галимнәр, без зур галәмәтләргә якынлашабыз, дип тә әйтә. Кече галәмәтләр дигәннән, вакытның тиз узуын әйтә алабыз. Моны барыбыз да сизәдер. Рәсүлебез үз хәдисендә: «Кыямәт көне алдыннан вакытның тизәюен сизәрсез. Бер ел – бер ай, бер ай – бер атна – бер көн, бер көн шырпы януына тиң булыр», – дигән. Вакытның бәрәкәте бетәчәк. «Зират кырыеннан, кабер кырыеннан үтеп барган кеше, шул каберге карап: «Мин шушында булсам иде», – дип әйтмичә, кыямәт көне җитмәс, дигән мәгънәдәге хәдис тә бар. Ягъни дөнья мәшәкатьләре күбәеп, авыраеп, кешеләр үзләренә үлем теләр. Шулай ук кыямәт көне җитәрәк үлемнәр һәм аеруча кеше үтерүләр артыр дип тә әйтелә. Пәйгамбәребез әйтә: «Кыямәт көне алдыннан үтерүче кемне үтергәнен һәм ни өчен үтергәнен дә белмәс». Потларга табыну артыр. Бу хәзерге җәмгыятьтә дә юк түгел. Евфрат елгасы кибеп, аның төбеннән алтын чыгуын, кешеләрнең шунда баруын фаразлыйлар. Барган йөз кешенең туксан тугызы үтерелер, диелә һәм һәрбер кеше мине үтермәсләр дип уйлар.

Балалар ата-анасыннан өстен булыр дип тә әйтәләр. Шулай ук «Аллаһ, Аллаһ» дип әйтүче булганда, кыямәт көне җитмәс диелә. Рәсүлебез, кыямәт көне алдыннан бик күп ялганчылар һәм ялган артыр, дип тә кисәтә. Шулай ук кайбер сугышлар турында да хәдисләр бар. Йөрәкләрдә әманәт һәм иман югалуы да – ахырзаман билгесе. Бер сүз белән әйткәндә, намаз укылганда, мәчет-мәдрәсәләребез барда, Аллаһы Тәгаләбезне искә алырлык кешеләр булганда, кыямәт көне ерак дип уйларга җирлек бардыр, иншалла. Әмма пәйгамбәребез: «Бу галәмәтләр муеннан өзелеп төшкән мәрҗән бөртекләре кебек берсе артыннан берсе тиз килер», – ди. Хәтта кулына ризык тоткан кеше аны кабарга да өлгермәс.

:: Ахырзаман җиткән көн нинди булыр? Аның тасвирламасы бармы?

– Рәсүлебезнең хәдисләрендә һәм Коръәни Кәримдә кайбер тасвирламалары кителә. Күз алдына китерү өчен, кыямәтнең менә шушы ахыргы ун билгесен белергә кирәк.

Дәҗҗал – ялганчы чыгуы, Гайсә галәйһи вәссәламның яңадан килүе, дуһан дигән төтеннең дөньяны басуы, кешеләр белән сөйләшүче дәббә дигән хайванның чыгуы – кыямәт көнне шушы билгеләр күзәтелер. Кояш көнбатыштан чыгар, ул әле өч көн тоткарланыр. Ефәктән дә йомшак җил исеп, күңелләрендә аз гына булса да иман булганнарны бер үлем белән алып китәр. Бу галәмәтләр берсе артыннан берсе бик тиз килер. Шушылар булып узгач, кешеләр яшәвен дәвам итәр әле. Кемдер эшкә барыр, кемдер баласын бакчага илтер, яңа килешүләр төзелер... Беркем дә бу көн килгәндер дип уйламас. Аллаһы Тәгалә кыямәт көнендә адәм баласыннан: «Әй, адәм баласы! Мин сиңа хатын бирмәдемме, зур хайваннарны буйсындырмадыммы, дөнья белән хозурланырга мөмкинлек бирмәдемме?» – дип сорар. Адәм баласы исә: «Бирдең, Раббым!» – дияр. «Ә син минем белән очрашырмын дип уйладыңмы соң?» – дип кабат сорар Аллаһы Тәгалә. «Юк», – дияр кеше. Менә шуннан соң Аллаһы Тәгалә: «Син мине оныткан кебек үк, мин дә сине кыямәт көнне онытырмын», – дияр. Әйткәнемчә, кыямәт көне кисәк киләчәк. Исрафил фәрештә сурга өрер. Дөнья коточкыч куркуга батар. Бу тавышны бөтен җан иясе ишетер. Сурга беренче тапкыр өрелгәч, бөтен җан ияләре үләчәк. Хәтта Үлем фәрештәсе дә үз җанын үзе алыр. Икенче сурга өрелгәч, бөтен җан иясе яңадан терелер һәм Мизан мәйданына ашыгыр. Монда инде кешеләр дөньяда кылганнары өчен җавап тотар. Күкләр ярылыр, диңгез-океаннар янар, җирләр теткәләнер, җир өсте тип-тигез булыр, бер тау калмас – ахырзаман шундый булыр. Пәйгамбәребез, бу көнне барча кеше ялангач булыр, ди. Гайшә анабыз моны ишеткәч: «Йә, Рәсүлем! Башка ирләр миңа карар бит», – дигән. Пәйгамбәребез исә: «Ул вакытта кешенең кешедә эше булмас», – дип җавап кайтарган. Яшь баланың чәче агарыр, йөкле хатын баласын төшерер – кыямәт шуның кадәр куркыныч булыр, аннан качып котылыр урын булмас. Бер яклаучы – Аллаһы Тәгалә һәм бары Ул гына хөкем итәчәк. Кеше әнә шул вакытта Коръәндә әйтелгәннәрнең дөрес булуын аңлаячак. Ләкин бик соң булыр.

:: Хәзерге заманда ахырзаман билгеләре күзәтелә дип әйтеп буламы?

– Вакытның тиз узуы, ялганчыларның артуы, үтерүчеләр күбәю – бу галәмәтләрне күзәтеп торабыз. Хәзер урта галәмәтләр бара. Ахырзаманның билгеле бер көне-сәгате юк. Аллаһы Тәгалә Локман сүрәсенең бер аятендә Үзе генә белә торган биш яшерен нәрсә турында хәбәр итә. Иртәгәсе көнне нәрсә буласын, кемнең, кайда һәм ничек үләсен, явым-төшемнең кайда һәм күпме дәрәҗәдә буласын, әни карынындагы баланың бәхетлеме-юкмы икәнен, төсен, кыяфәтен һәм кыямәт көненең кайчан киләсен – Аллаһы Тәгаләдән башка болар турында беркем бернәрсә белми! Моны белсәк, яшәү күңелле булмас иде. Мөселман кешесе һәрвакытта да моңа әзер булырга тиеш.

ӘҢГӘМӘ ТУЛЫСЫНЧА VATANTAT.RU САЙТЫНДА

Октябрь аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Җом	03:41	05:46	14:32	17:18	19:00
2	Шим	03:43	05:48	14:30	17:16	18:57
3	Якш	03:45	05:50	14:28	17:13	18:55
4	Дүш	03:48	05:52	14:26	17:11	18:52
5	Сиш	03:50	05:54	14:24	17:08	18:49
6	Чәрш	03:52	05:56	14:22	17:06	18:47
7	Пәнҗ	03:54	05:58	14:20	17:03	18:44
8	Җом	03:56	06:00	14:18	17:00	18:41
9	Шим	03:58	06:02	14:16	16:58	18:39
10	Якш	04:00	06:04	14:14	16:55	18:36
11	Дүш	04:02	06:06	14:12	16:53	18:34
12	Сиш	04:04	06:08	14:10	16:50	18:31
13	Чәрш	04:07	06:10	14:08	16:48	18:29
14	Пәнҗ	04:09	06:12	14:06	16:45	18:26
15	Җом	04:11	06:14	14:05	16:43	18:24
16	Шим	04:13	06:16	14:03	16:40	18:22
17	Якш	04:15	06:18	14:01	16:38	18:19
18	Дүш	04:17	06:20	13:59	16:35	18:17
19	Сиш	04:18	06:22	13:57	16:33	18:15
20	Чәрш	04:20	06:24	13:55	16:31	18:12
21	Пәнҗ	04:22	06:26	13:53	16:28	18:10
22	Җом	04:24	06:28	13:52	16:26	18:08
23	Шим	04:26	06:30	13:50	16:24	18:06
24	Якш	04:28	06:32	13:48	16:21	18:04
25	Дүш	04:30	06:34	13:46	16:19	18:02
26	Сиш	04:32	06:36	13:44	16:17	17:59
27	Чәрш	04:34	06:39	13:43	16:14	17:57
28	Пәнҗ	04:36	06:41	13:41	16:12	17:55
29	Җом	04:38	06:43	13:39	16:10	17:53
30	Шим	04:39	06:45	13:37	16:08	17:51
31	Якш	04:41	06:47	13:36	16:05	17:50

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Мәхәббәтле бул!

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:
«Алар белән күркәм [мөнәсәбәтләрне саклап] яшәгез [аларга карата инсафлы булыгыз һәм матур сөйләшегез]. Әгәр аларны өнәмәсәгез, [янә дә сабыр итегез] [чөнки] сезгә, бәлки, нәрсәдер ошамыйдыр, әмма Аллаһ шуңа да бик күп хәер тәкъдир иткән [булуы мөмкин, тик сез генә моны белә алмыйсыз].
«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:19
Сөекле пәйгамбәребез дә үз хатыннарына матур сүзләр белән генә дәшкән, алар белән шаярта торган булган, ихтирам иткән, аларга тавыш күтәрмәгән, ачуланган чакта да, дәшми торган булган. Шулай булгач, хөрмәтле ир-атларыбыз, сайлап алган хәләл җефетләребезгә матур сүзләрне кызганмасак иде. Йөрәктәге хисләр телдә дә чагылырга тиеш. Мәхәббәтле булыйк!

Чулпан ГАРИФУЛИНА әзерләде

РАФИЛ ҖӘЛӘЛИЕВ:

«ТӘНКЫЙТЬКӘ ТҮЗӘРГӘ ТУРЫ КИЛӘ»

Бүгенге «Ни хәл?» сәхифәсенә кунакка «Башваткыч» тапшыруын алып баручы, җырчы Рафил ҖӘЛӘЛИЕВне дәштек. Телевидение, мәҗлесләр, эстрада турында, хатыны – җырчы Эльмира Гыйльфанова белән икесенә иң еш бирелә торган сорау, популярлык хакында сөйләштек.

:: Ни хәл соң?
– Хәлләр әйбәт. Әле менә съемкалардан кайтып кергән юк. Көн-төн диярлек «Башваткыч» тапшыруының яңа чыгарылышларын төшерәбез. Катнашырга теләк белдерүчеләр шундый күп.

:: Әлеге тапшыруны алып бара башлавыңа бер елдан артты. Ничек соң: ошыймы, ошаталармы?
– Ошый. Тапшыруның командасы бик әйбәт, эшли башлаганнан бирле яхшы мөгамәләдә без. Алар миннән канәгать булса, мин күптән канәгать инде. Бер дә уйламаган җирдән бу командага килеп кушылдым бит.

:: Мәҗлесләр дә алып барасыз. Быел җәй эшегез күп булдымы?
– Җәй яхшы узды, Аллага шөкер. Үзизоляциядә утырып арыган халык ачылып киткән төсле тоелды. Август мәҗлесләр саны буенча 2019 елның декабрендә куйган рекордны да узып китте. Җәйнең өч ае һәм сентябрьдә ел да эш күп була инде ул, аннан бераз кими төшә.

:: Алып баручылардан башка мәҗлес уздырулар сирәгәя.
– Әйе, бу чыннан да шулай. Хәзер бәйрәмнәрнең сыйфаты, зәвыгына игътибар артты. 15 еллап кайныйм инде мин бу өлкәдә, үзгәрешләр хәйран күп. Элегрәк бәйрәм билдән түбән мәзәкләргә корыла иде, ә хәзер башкача.

:: Хәзер Инстаграмда шәхси тормыш кирәгеннән артык ачып салына кебек. Кешегә дә шул гына кирәк шикелле. Сезгә дә «Бәби алып кайтасызмы әле?» – дип язучылар шактый...
– Кеше белән аралашуның билгеле бер тәртибе, кагыйдәләре бар. Әдәп, тәрбия, зәвык дәрәҗәсеннән чыгып,

кеше аларны йә үти, йә юк. Нинди дә булса сорау бирер алдыннан, кемдер аның артыннан ни буласын уйлый, кемдер – юк. Сүзне әйткәнчә, башта: «Бу сүзләрем белән кешенең авырткан җиренә кагылмыйммы икән?» – дип уйларга кирәк.

Бәби алып кайтуга килгәндә, әгәр син билгеле бер гаиләнең тормышын күзәтеп барасың икән, аларның кайчаннан бирле бергә яшәүләрен чамалыйсың. Әгәр балалары юк икән, димәк, ике сәбәп бар: беренчесе – теләмиләр, икенчесе – башка сәбәп. Бу теманы күтәргәндә, күңелләренә авыр түгел микән? Моны да уйларга кирәк, әмма уйламыйлар.

> Тамашачы белән артист арасындагы якынлык элек тә булган инде ул. Хәзер комментарийлар калдырсалар, элек җырчыларга хатлар язганнар. Мондый якынлык шәхси тормышка үтеп керә башлады...

:: Үзегезне популяр дип әйтә аласызмы?
– Безне белүчеләр, үз тамашачыбыз бар. Ләкин Салават абый белән чагыштырсак, юк, популяр түгел без.

Блиц-сораштыру

– Эльмира нинди хатын?
– Әйбәт! Минем өчен идеаль кеше.
– Сезнең гаиләдә «баш», «муен» төшенчәләре бармы?
– Кеше арасында чакта, бар. Эльмираның миннән алдан башлап сүз әйткәне юк. Ә өйдә – юк. Без бик күп сөйләшәбез, киңәшләшәбез. Мин – баш, димәк, мин хаклы, дип, киреләнеп йөрү юк. Тормыш шулай барырга тиеш инде ул.
– Балачакта нәрсә турында хыяллана идең? Чынга аштымы ул?
Беренче тапкыр суррогат әни булганда Оляга килешү нигезендә 900 мең сум акча түләргә тиеш булганнар. Тик ул игезәкләр тапкан. Шуңа күрә гонорарга тиешле сумманың тагын 30 проценты өстәлгән. Бүген дә ул шул ук суммага бала табып бирергә риза. Киләсе атнада дүшәмбе күрешергә килешеп саубуллаштык. «ВК» социаль челтәрендә үз хезмәтләрен тәкъдим иткән берничә суррогат ана белән дә элемтәгә кердек. Барысы да диярлек бу адымга тиз арада акча кирәк булганга баруын әйтә. Араларында берсе килешү төземичә генә хезмәттәшлек итеп булмасмы икән дип кызыксынды. Шәхси мәгълүматларының беркайда да күренүен теләми икән. Ул сиңа бала алып кайтып бирә, син аның «тапкач, баланы бирәм» дигән вәгъдәсенә ышанырга тиеш буласың. Моның өчен яхшы гына ташлама ясарга да вәгъдә итте.

Әлмәттә яшәүче Җәләловлар да, ун ел тилмергәннән соң, суррогат әни табарга булган. «Тәрбиягә бала алып та булыр иде. Тик иремнең үз баласын үстерәсе килде», – ди Әлфия ханым (исеме үзгәртелде). Үзләренә бала табып бирерлек хатынны суррогат әниләр агентлыгы аша таба алар. «Организмы яшьрәк булыр дип, 26 яшьлек хатын-кызны сайладык. Үзенең ике баласы бар. Йөклелек чоры яхшы узды, килешенгәнчә 1,1 млн сум акча түләдек. Суррогат әнидән бала таптыруыбызны күршеләр түгел, якын туганнарыбыз да белмәде. Бала туганчыга кадәр ясалма корсак киеп йөрдем», – дип шаккатырды әңгәмәдәшем. Бактың исә, суррогат әниләр хезмәте тәкъдим иткән клиникаларда шундый ясалма корсаклар сатыла икән. Бәясе уртача 7–8 мең сум. Онлайн кибетләрдә аларның 2–3 меңлекләрен табарга була.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

СУРРОГАТ АНА УРАМНАН КЕРМИ

Суррогат ана нинди булырга тиеш? Ул баласын генетик ата-анасына тапшырудан баш тартса, ни эшләргә? Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының репродуктив сәламәтлек буенча штаттан тыш баш белгече, Татарстан Республикасының атказанган табибы Фирая САБИРОВА иң актуаль сорауларга ачыклык кертте.

:: Фирая Маратовна, соңгы елларда суррогат аналарга мөнәсәбәт үзгәрдеме?
– Унбиш еллап элек суррогат ана булу халык тарафыннан ниндидер гайре табигый күренеш кебек кабул ителә иде. Элегрәк бу хакта ничектер ачыктан-ачык сөйләшү дә булмады. Бу ысулдан файдаланган кешеләр дә әлеге адымга баруын сер итеп сакларга тырыша иде. Бүген исә суррогат аналарга мөнәсәбәт йомшара төште. Халык арасында да моңа аңлап караучылар саны арта бара. Җәмгыятьтә суррогат анага карата тискәре караш тудыруда массакүләм мәгълүмат чараларында, интернетта таралган уйдырма, күпертелгән мәгълүматлар, бу хакта төшерелгән кинофильмнарның да өлеше зур. Аеруча соңгылары чынбарлыкны бозып күрсәтә.

:: Шулай да суррогат аналар арасында, бала тапкач, сабыен генетик ата-анасына бирүдән баш тартканнары юкмы? Хатын-кызның тугыз ай буе күкрәк астында йөрткән нарасыен, табуга ук, башка кешегә тапшыруын күз алдына китерү кыенрак...
– Бездә суррогат ана булу программасы 2005 елда гамәлгә ашырыла башлады. Шуннан бирле шундый бер генә очракның да күзәтелгәне булмады. Сүз уңаеннан шунысын да искәртим: суррогат ана белән карындагы бала арасында бернинди генетик бәйләнеш юк.

:: Суррогат ана хезмәтенә, гадәттә, кайсы очракларда мөрәҗәгать итәләр?
– Иң беренче чиратта бу мөмкинлектән билгеле бер сәбәпләр аркасында аналыгын алдырырга туры килгән хатын-кызлар файдалана ала. Хатын-кызга ана булырга комачаулаган ниндидер генетик авырулар булганда, йөклелек гүзәл затның гомеренә куркыныч тудырган очракта да бу ысул рөхсәт ителә. Җиде-сигез тапкыр ЭКО (ясалма орлыкландыру) ясаганнан соң да кайбер хатын-кыз йөккә уза алмыйча тилмерә. Андый чакта да суррогат ана хезмәтеннән файдалану турында уйланырга җирлек бар. Ә менә фигура бозмыйм дип суррогат әниләргә мөрәҗәгать итә алмыйлар.

:: Алар барыбер үз дигәненә ирешәдер ул. Хәзер интернетта суррогат ана булып, бала табып бирергә вәгъдә иткән әллә никадәр агентлык, шәхси игъланнар очратырга мөмкин...
– Кызганыч, андый күренеш тә бар шул. Әмма нормаль агентлык барыбер закон нигезендә эшләргә тиеш. Без үзебез суррогат аналар табып, сайлап алырга ярдәм иткән агентлык белән хезмәттәшлек итәбез. Суррогат ананы сайлап алу – бик зур хезмәт. Ник дигәндә, бу эшкә тотынганчы, иң элек суррогат ана булырга җыенган хатын-кызның бу адымга ни сәбәпле баруын, аның нинди максатларны күздә тотуын, бу адымга рухи яктан ни дәрәҗәдә әзер булуын ачыкларга кирәк. Әгәр генетик ата-ана суррогат ана булырга теләгән теләсә кемгә мөрәҗәгать итсә, кыен хәлдә калырга мөмкин. Шуңа күрә моның белән махсус агентлыклар шөгыльләнергә тиеш.

:: Суррогат ана булырга теләгән хатын-кызга нинди таләпләр куела?
– Иң беренче чиратта, булачак суррогат ананың моңа кадәр инде бала тапкан булуы, ягъни үз балаларының да булуы шарт. Бу иң элек ялган, алдау очракларын булдырмас өчен эшләнә. Әйтик, бала табарга сәләтсез булган хатын-кыз шушы ысул белән шәхси проблемаларын да хәл итәргә маташырга мөмкин бит. Бу мәсьәләнең икенче ягы да бар. Суррогат ана машина түгел, ул да – шул ук хисчән хатын-кыз. Баласын табып, генетик анасына тапшырыр чак җиткәч, аңа рухи яктан бик авыр булырга мөмкин. Янында шушы аналык хисләрен кичерергә үз баласы булса, аңа күпкә җиңелрәк булачак. Моннан тыш, суррогат әни булу өчен хатын-кызның 18–35 яшьлек, психик һәм физик яктан саусәламәт булуы шарт. Аның эчү, тарту кебек начар гадәтләре булмау, наркотиклар кулланмавын әйтеп тә торасы юк.

:: Суррогат ана булу мәҗбүри медицина иминияте полисына кертелгәнме?
– ЭКОдан аермалы буларак, суррогат ана булу мәҗбүри медицина иминияте полисына кертелмәгән. Гадирәк итеп әйткәндә, хөкүмәт суррогат анага тотылган чыгымнарны капларга тиеш түгел.

:: Татарстанда суррогат анадан туган ничә бала исәпләнә?
– Республика күләмендәге саннарны төгәл генә әйтү кыен. Безнең карамактагы ике клиникада әлеге юл белән елына 20ләп бала дөньяга аваз сала.

:: Татарстанда суррогат ана хезмәте күпмегә төшә?
– Бу хезмәтнең төгәл суммасы бик күп төрле факторларга, шул исәптән суррогат ананың бу ярдәме өчен күпме гонорар алырга теләвенә бәйле. Ул туачак баланың генетик ата-анасы белән үзара килешеп билгеләнә. Шулай да республика күләмендә уртача алсак, бездә суррогат ана хезмәте 1 миллион сум чамасына төшә. Моннан тыш генетик ата-ана аңа ашау-эчү, витамин, дарулар алу өчен ай саен өстәмә акча күчереп торырга да тиеш.

Суррогат ана баласын генетик ата-анасына тапшырудан баш тарткан очракта ни эшләргә?

Сорауга юрист Равил ХАРИСОВ җавап бирә:
– Бу очракта иң элек суррогат анага язмача дәгъва җибәрергә кирәк. Ул аннан соң да баланы бирүдән баш тартса, баланың генетик ата-анасы судка шикаять язарга тиеш. Әгәр ул баланы үзенә яздырган булса, сабыйның генетик ата-анасына аның биологик әти-әнисе булуын исбатлау авыр булачак. Җавап бирүченең – бу очракта суррогат ананың – эмбрионны үзенә күчереп утыртуга ризалык бирүе дә дәлил булып санала алмый. Ягъни суррогат ананың баланы күтәреп, табып бирергә ризалык бирүе ул сабыйны аларга мәҗбүри тапшырырга тиеш дигән сүз түгел. Россия Гаилә кодексының 52 нче маддәсендәге 3 нче пунктта шулай диелгән. Суд суррогат ана белән ике арада төзелгән килешүне дә дәлил буларак кабул итмәскә мөмкин.

ЯЗМА ТУЛЫСЫНЧА VATANTAT.RU САЙТЫНДА

ЙӨРӘГЕМӘ – УНСИГЕЗ

Гомер көзен һәркем үзенчә үткәрә. Берәүләр дөнья мәшәкатьләренә чума, балаларына ярдәм итәм дип эшләп йөри. Икенчеләр оныкларын караша, өченчеләр үз көенә яши. Барысын да бер нәрсә берләштерә – тормыш тәҗрибәсе. Халыкара өлкәннәр көне уңаеннан шундый тәҗрибәле, әле дә тормыш активлыгын югалтмаган өлкәннәребез белән аралаштык.

БЕРГӘ РӘХӘТ

Саба районының Эзмә авылында яшәүче Рафис Әскәровка үз яшен биреп булмый. Әле дә егет ул! Кулыннан килмәгән эше юк. Каралты-кураларын тәртиптә тота, балта эшенә дә оста. Машина да йөртә. «Сез пенсиядәме?» – дип тә сорыйлар икән. Чынлыкта Рафис абыйга – 82 яшь. Ул үзенең яшь калу серен хәрәкәттә дип аңлата. Шуңа өстәп, хатынын да мактап куя.

– Ирләрнең тормышы – хатыннар кулында, – ди хатыны Сания апа. – Тикмәгә генә, ирне ир иткән дә – хатын, чир иткән дә – хатын, димиләр. Рафис абыегызны аңлап, санлап, хөрмәт итеп яшәдем. Ул да миңа начар булмады. Без – хәзерге кебек 5–6 ел йөреп түгел, 2–3 көн очрашып гаилә корган кешеләр. Шөкер, аңа карап тормадык, тормышыбыз үкенерлек булмады. Ирем гел яшьләр янында йөрде, хәзер дә шулай. Оныклар белән яшәрә. Йорттагы эшне кешегә эшләтмәдек. Рафисымның кулы алтын.

Теләче районының Алан кызы үзләренә эшкә килгән егеткә бер күрүдә гашыйк була. Ирдән китү, аерылу кебек уйлар беркайчан да башына да кереп чыкмый.

– Ул чакта тормыш җиңел түгел иде. Яшьлек белән авырлыкны сизмәгәнбез генә. Юкка-барга ачуланышып, үпкәләшеп яшәмәдек. Дүрт балабыз булды. Олы кызыбыз Илүсәм артыннан туган улыбыз Илгизәрне 9 яшендә югалттык. Кан рагы, диделәр. Аннан соң тагын ике кыз алып кайттык, – ди Сания апа.

Еллар узса да, арадагы мәхәббәт хисе югалмаган. Рафис абый әле дә яшьлектәге кебек романтик икән, хатынына чәчәкләр бүләк итә.

– Ир-атны ир итәргә кирәк. Әгәр шуны эшләсәң, бәхетле гомер кичерәсең. Ярату белән генә яшәп булмый. Арада хөрмәт, ышаныч булу кирәк. Иремнән серем дә булмады. Ул – мине, мин аны аңлап яшәдек, – ди Сания апа. – Яшьлек үтә дә китә ул. Картлыкта янәшәңдә ярың булу кирәк. Бер-беребезне югалту турында уйларга да куркабыз. Икәү бергә рәхәт.

ҮРНӘК ӘБИ

Туры сүзле, чисталыкны яратучы, һәр нәрсәгә үз фикере булган Гөлсинә Хөсәенова Арча районының Кышкар авылында яши. Күпләр аны Гөлназ Сәфәрова әбисе буларак та белә. Гөлсинә апа үзенә ничә яшь булуын кешегә әйтми икән. Җавабы бер: хатын-кызның яшен сорамыйлар.

– Безнең әби бик акыллы ул. Гомере буе авылда мал табибы булып эшләде, – дип сөйли оныгы Гөлназ. – Чаллыда туып-үскән кыз булса да, бабаемны очраткач, Арчага күченеп кайта. Өч бала үстерәләр. Әнием Резедә, Римма апам һәм абыем Илһам туа. Хәзерге көндә әбиемне Илһам абый белән киленебез тәрбияли. Алар – әбигә иптәш. Бергә яшәмәсәләр дә, гел хәлен белеп, кайгыртып торалар.

Гөлназ үзе дә әбисенә кунакка еш кайта. Аның янында бик рәхәт, ди.

– Тәрбия – хатын-кыз кулында. Әбием, әнием мисалында мин моның шулай икәнен аңладым. Әти кеше баш булса да, гаиләдә күп әйбер әнидән тора. Әби балаларына дөрес юл күрсәткән. Аңа сокланмый мөмкин түгел. Бөтен эшне җиренә җиткереп эшли. Әле дә нәркөн, иртә торып, идәннәрне юып ала. Әбигә булышам, җыештырам дип кайтсаң да, эш калмаган була. Эш белән хәрәкәттә булырга тырыша, – ди Гөлназ.

Оныклар, яратып, аны «Гөлсинә Зәкиевна» дип йөртәләр икән. Гөлназ әбисенең олыгайгач та, күңеле яшь калуга соклана.

– Аның һәр сүзендә мәгънә ята. Ул – конкрет кеше. Нинди генә кыен хәл булса да, бөтен серемне аңа сөйлим. Әби дөрес юл күрсәтә. Гаилә тормышына кагылышлы төпле киңәшләрен дә әйтеп тора. Элек мин төрле шәһәрләргә еш йөри идем. Хәзер әби кушмый. «Гаилә учагын сакла. Казанда эшлә, ерак юлга чыкма. Бәйрәмнәрне атнага бер алып барсаң да ярый», – дип тора. Газеталар укый, телевизор карый, – ди Гөлназ.

Гөлсинә апаның хәтере дә яхшы икән. «Әбиемне продюсерым дисәм дә була», – дип шаярта Гөлназ.

– Әле беркөнне эшлисе эшемне онытканмын. Шуны белгәч, эшләремне миңа язып калдыр, исеңә төшереп торырмын, ди. Аның зарланганын бер дә ишеткәнем юк. Ул гомере буе эшләгән. Әби белән мине күренмәс җепләр бәйли, – ди ул. – Беренче онык булгангамы, ул миңа бик якын. Олыгайган көнендә дә картаерга ашыкмавы, заман белән бергә атлавы ошый миңа. Ни дисәң дә, бар да үзебездән тора икән. Әбине мисал итеп алам да тагын бер сокланам. Бабайсыз калуына да 32 ел инде. Әмма ул беркайчан да төшенкелеккә бирелмәде. Балаларына терәк булып, аларны яратып яши. Аларны дөрес тәрбияләгәнгә, бәхетле картлык кичерә.

САБЫРЛЫК КИРӘК

Азнакай районының Карамалы Елга авылында яшәүче Тәслия әби белән Язкәр бабай Җиһаншиннарны дөньяга җырчы Гүзәлем һәм Салават Миңнехановлар танытты. Аларның клибында төшкәннән соң әллә кайдан танып эндәшәләр икән. Кызганыч, ике ел элек Язкәр бабай үлеп китә. Тәслия апа, ирен сагынып, бер ел буе елый.

– Безнең әни кебек кеше башка юк, – ди килене Ләйлә. – 27 ел яшәп, Аллага шөкер, ник бер тапкыр сүзгә килик?! Аның бер генә авыр сүз дә әйткәне булмады. Йокыбыз туйганчы йоклатты, эшләгез, димәде. Без торуга токмачлы аш пешерер иде. Әнигә мин бик рәхмәтле. Үзебезгә торырга да чакырабыз, тик әни өен ташлап китми.

Тәслия әби белән Язкәр бабай 5 бала үстерәләр. Бер уллары, армиядән кайткач, фаҗигале төстә вафат була.

– Бала хәсрәте беркайчан да узмады. Гомер буе күңелемне төшермәскә тырыштым, уен-көлке, эш белән хәсрәтемне бастым. Кычкырып елаган чаклар да күп булды, әмма бирешмәдем. Язкәремнең янәшәмдә булуы, яратып яшәве ярдәм итте, – ди Тәслия апа. – Үзем дә үлеп гашыйк булып чыктым бит мин аңа. 19 яшемдә идем. Язкәрнең армиядән кайткан вакыты. Бер кич озата кайтты. Сөйләшкәндә, көзсез өйләнмим, дигән иде. Мине ошаткандыр инде, озак та тормадык, өйләнештек. 62 ел бәхетле яшәдек. Мин гомерем буе терлекчелектә эшләдем. Ирем тракторчы иде. Хәзер инде тормыш рәхәт. 84 яшемне тутырдым, ә күңел гел унсигездә кебек. Дәрт тә бар, дәрман да бар. Тагын клипка төшәргә чакырсалар, барыр идем. Районга килгән бер җырчының концертын да калдырмыйм. Чәчәкләр бүләк итәм. Мине алар үзләре дә таный инде.

Әбекәйнең осталыгын телевизор экраннары аша күрмәгән кеше калмагандыр инде. Ул уйнаганда, артистларын читтә торсын! Тормышта да шундый шат күңелле икән. «Сәламәтлегем зарланырлык түгел. Рәхәт яшим. Җаным тыныч, балаларым янәшә. Бер көн дә ялгыз кундырмыйлар. Ишегалдым тулы кошкорт. Яшисе дә яшисе генә», – ди.

Яшьләргә киңәшен дә бирде:

– Хәзер сабырлык юк. Зур итеп туйлар ясап кияүгә чыгалар да икенче көнне үк аерылышу турында уйлый башлыйлар. Тормышта ни булмас, түзә белү дә кирәк. Без дә кочаклашып, үбешеп кенә тормадык. Балалар булгач, аларны кеше итик дип тырыштык. Безгә хөкүмәт тә булышмады. Ә хәзер рәхәт! Тормыштан ямь табып, яратып, үкенмәслек итеп яшәгез!

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ФЛЕРА ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА: «ЯЗУЧЫНЫ АҢЛАП, КЕМ КАДЕРЛӘГӘН?..»

Язучы хәләте, яшәеше, кадерләнүе һәм кадерсезләнүе турында күптән түгел 90 яшен тутырган ветеран шагыйрә Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНАдан да үтемлерәк итеп әйтеп бирүче булмастыр. Тормышның ачысын да, төчесен дә татыган әдип бүген нинди уй-борчулар белән яши – без әнә шуларны белештек.

Анна Арахамия

:: Флера апа, «Казан утлары»нда «Коллык зинданы» поэмасы басылгач, сезнең иҗатка игътибар бермә-бер артты. Бу гаҗәпләндермәдеме?

– Мин соңгы биш-алты ел буена урамга да чыкмыйча өй өтерләмәнендә гел язып утырдым. Язучылар берлеге тирәсеннән шалтыратучы да булмады. Әле шушы атнада гына Ркаил Зәйдулла шалтыратып, 90 яшьлегемне үземнең туган районым – Азнакайда уздыру мөмкинлеген әйткән иде, мин әлегә ризалык бирмәдем. Чөнки башта миңа корылган каршылыкларның сәбәпләрен ачыклыйсым килә. Ә моның өчен күп вакыт кирәк. 2012 елдан бирле шундый зур күләмле иҗади байлыгымны ни өчен торгынлыкта тотуларын беләсем килә. Мин бит – бу язучылар дөньясына санап бетергесез игелекләр кылган кеше! Минем хакимият каланчасыннан чаң сугып язылган «Яну дәверләрендә» дип исемләнгән китабымда да 107 поэма бар. Ә 2016 елда дөнья күргән «Вөҗдан үре – йөрәк түре»ндә – татар әдәбиятының иң зур, коточкыч язмышлар кичергән галиме Гали Рәхимгә багышланган шигъри роман һәм «Ак калфакның табылган чагы» дигән өр-яңа әсәрләрем бар. Бары үз мәнфәгатьләрен генә кайгырткан җитәкчеләр бу әсәрләргә игътибар итеп тормады. Хәер, алдагы елларда язылган китапларым да Ватан язмышы белән сугарылган, медальле, таныкламалы иде. Ә әлеге дан караклары тарафыннан үләт чүплегенә аткарылган «Яну дәверләрендә»м исә, Кол Гали һәм Тукай белән көч сынашып, «Ел китабы» бәйгесендә өченче урынны алды. Шул бәйгене алып баручы хатын-кыз: «Сезнең китабыгыз беренчелекне алды, ләкин аны Тукайдан, Кол Галидән алда уздыра алмадык, зинһар, күңелегезне төшермәгез», – диде. Кая инде күңел төшерү! Шалтыратып, шулай әйтү дә – үзе бер бәя бит ул! Әмма язучылар арасында аның Минтимер Шәймиевкә багышлап язылган битен сызгалап, чүп савытына ташлаучылар булды. Берләктә яклаучым булмагач, мондый очракларны ялгызым кичерергә туры килде миңа. Әле яңа гына сайланган бу саф күңелле ике талантлы шагыйрьне (Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, аның урынбасары Илсөяр Иксанова. – **Ред.**) үземнең кан-яшьле язмышым өчен интектерәсем килми минем. Алар бит үзләре дә, юбилей өчен хакимияттән бернинди акча каралмаган, диләр. Шуңа күрә мине Азнакайга сөрәләр дә! Ләкин үземнең әтием оештырган Азнакаема теләсә кайчан кайтып керә алам мин. Бу «Яну дәверләрендә» дигән китап Азнакай, Актаныш, Арча маршрутлары буйлап мәртәбәгә, данга ирешәчәк әле… Мин моңа ышанам.

:: Иҗатым өчен дә, яшәвем өчен дә гомер буе көрәшергә туры килә, дисез. Нинди куркыныч яный соң сезгә?

– Һәрхәлдә үлем түгел!.. Минем бик отышлы тузым бар. Әтием – сугышка үзе теләп китеп, дүрт ел буе алгы сызыкта сугышып, Украинаны фашистлардан азат иткәндә, җир-күкләре белән тоташ утлы гарасатка йотылган кырлар буйлап атакага ташланган командир! Аның соңгы хаты шушнан килгән иде: «Без атакага ташланганда кырыктан артык идек… Бу минутта нибары җидегә калдык… Барыбыз да тереләй янабыз… Бу минем соңгы хатым булыр инде…» – диелгән иде хатта.

Сугыштан соң мин уналты яшемнән Кемерово шахталарына китеп, тирәнлеге чакрым ярымга сузылган җимерек шахталарда, тимер юл, урман кисү эшләрендә эшләп, җир күтәрмәс газаплар чиккәннән соң, әтием көл-күмергә әйләнгәнче сугышкан, ирек яулап биргән Украинага юл тоттым. Әлбәттә, ул елларда Украина инде гөл-чәчәкләргә күмелеп утыра иде. Нинди язмышлар, уй-ниятләр белән килүемне белгәч, мине дә ул чорда күтәреп алдылар. Әмма хәзер сугыш бара анда. Ләкин үз илемдә яшәгәндә үк үги явызлыкка дучар ителеп, кара урманнарда куна калып, бүреләр арасында яшәгән бала идем бит мин. Татарстан китап нәшриятында 17 китабым тупланган 6 томлыгымны дөньяга чыгару максаты белән барсам, мине инде фашистка әйләнеп беткән Зеленский да аңлар, ярдәменнән ташламас иде. Әгәр ярдәм итә алмый икән, һич югы хәер эстәргә рөхсәт итәр. Алай да булмаса, хәрби комиссариат ярдәм итәр миңа. Әтием генә түгел, армия сафларында җиде ел хезмәт итеп, япон сугышларында да катнашып, әллә нинди батырлыклар кылганнан соң, минем арттан кайткан ирем дә Донбасс шахталарында күмер кисте. Көне-төне эшләп, фатир алып, шуны Казанга алмаштыру бәхетенә ирештек без ул чорда.

> Ул елларда да безнең «юләрлек»тән бик күп язучылар файдаланды. Кеше өчен түгел, үзе өчен дә бармакка-бармак сукмаган хатын-кызлар арасында: «Син бит – шофер хатыны гына!.. Син бит – тегүче генә!..» – дип, артымнан кычкырып калучылар булды.

Әйе, берлек нужасы белән йөргәндә, ялгышып кына барып керсәң дә, чәй эчкән арада хәйләкәр хатын-кызлар сандыкларыннан өчәр-бишәр күлмәклек чыгаралар иде. Ә мин матур тукымалар, андагы чәчәкләрне күреп сихерләнәм… Бер тиенемә дә кирәк булмаган хатын-кызлар армиясенә дистәләгән кием-салым җөйләдем. Ирем дә Ахуновлар белән дистәләгән еллар буена сузылган дуслыгыбыз хакына, 80 тәңкә окладка ун ел буе Язучылар берлегендә шофер булып эшләде. Бер тапкыр ял да алмады ул. Аңа карап берлек безгә фатир да, бакча да бирмәде, юбилей кичәм дә үткәрелмәде. Хәер, бер тапкыр, 2006 елда, Милли мәдәният үзәгендә кичәм уздырылган икән. Зилә Вәлиева мәдәният министры булган еллар бу.

Иҗатым турында ихластан игътибарлап, белеп язылган йөзләгән бәяләмә бар. Аларны Гариф Ахунов, Хәсән Туфан, Әхсән Баян, Саҗидә Сөләйманова, Әдип Маликов, Зиннур Мансуров, Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, Гамил Афзал кебек олы шәхесләр язган. Архивым исә хәзерге көнгә чаклы Минтимер Шәймиевнең эш бүлмәсендә саклана. Ә менә томнарымны чыгара башларга дигән боерыклар ни өчендер үтәлми. Аның өчен Тукай бүләге лауреаты булу кирәк икән. Аны миңа 2005 елда ук бирә башлаганнар иде дә бит… Монысының җеп очын каян эзли башларга да белмим. Хәзер бит һәрбер чарасызлык хәрамга батты…

:: Язучылар берлегендәге иң өлкән кешегә игътибар җитәрлекме?

– Язучылар берлеге, минем күзлектән караганда, күптән күтәрәмгә калган ат хәлендә. Ни намуслы, ару-талуны белмәс Гариф Ахунов та, Туфан Миңнуллин да эшләп ярый алмады көйсез язучыларга. Язучы бит ул – атом бомбасы өстендә утырган пәйгамбәр кебек тынгысыз. Ә кем аларны аңлап, кызганып кадерләгән соң? Менә хәзер генә шигъриятнең күтәрәмгә калуын тоеп, ике намуслы, талантлы шагыйрьне сайлап куйдылар. Алар булдырабыз дип эшлиләр, көне-төне тырышалар. Ләкин аларның эше «Коллык зинданы» поэмасындагы кебек чүп базына йөтылачак, әгәр хакимият үзе дә төпкә җигелмәсә. Чөнки әле язу эшенә уен итеп караучылар күп. Бигрәк тә яшьләр арасында. Үземә килгәндә, үземне хәтерләп белгәннән бирле янудa. Миңа биш яшь чагында әнием белән икебезне Сәпәй хастаханәсенә илтеп салган әтием. Районны оештыручы буларак, үзе дә безнең янга еш кына кагылган, саклап кунып та калгалаган. Мин аңга килгәндә, тән тиреләрем, чәч-тырнакларым янып коелган иде. Үлде дип подвалга ук төшереп куйганнар. Әтием, ак япманың бер почмагы ачылып киткәнлекне күреп, кулын култык астыма тыгып караган һәм йөрәк тибешемне тойган. Врачларга да әйтеп тормыйча, мине моргтан урлап алып кайтып киткән. Мәрт сәфәрләре гизеп, аңыма килгәндә, урамда яз иде инде. Әниемне Сәпәйдән алып кайтып җирләгәннәр иде… Шуннан соң минем өчен якты дөнья мәхшәргә әйләнде һәм биш яшемнән күрәзәче булып киттем.

:: Сезнең иҗади дөньягыз белән якыннанрак танышыйк әле. Иртәгез ничек башлана? Иҗат итү өчен аерым вакыт билгеләнгәнме? Тормыш-көнкүрештә ярдәм итүчеләрегез бармы?

– Иҗади мөгамәләләр, аңлаешлы халык белән якыннан аралашып, тормышның төрле катламнарындагы авырлыкларны да, уңышларын да якыннан күреп сөйләшкәндә, үзгәрешләрне, уңышларны, җимерелешләрне чын күңелдән уйланып бәяли белгәндә көчәя һәм ныгый дип уйлыйм мин. Мәсәлән, «Яну дәверләрендә»не язарга да Азнакайдагы очрашулар сәбәпче булды. Берлек рәисе Фоат Галимуллин белән барган очрашулар вакытында ат заводына да кердек. Шунда бер искиткеч матур кыяфәтле тимеркүк ат янында дөньямны онытып адашып калганмын. Үзем белән бертуган Наилә апам да, Шаһәдәт җизнәм дә, Фоат Галимуллин да, кабат урап килеп, мине күзәтәләр икән. Шулчак Фоат Галимуллин: «Флера ханым, әллә поэма язып башладыңмы?» – дип сорап, мине сискәндереп җибәрде. Ә җизнәем: «Я, сеңлем, багышлап җибәр шушы тимеркүкне Минтимер Шәймиевка», – дип, яныма ук килеп басты. Шулчак апа, үртәлеп, җизнигә карады: «Кит моннан! Безнең әтиебез җигеп йөргән ат бит ул. Аның бердәнбер истәлеген кемгәдер бирәләрмени?!» – дип, яшьле күзләрен куллары белән каплады. Мин дә әчке дөньям белән әтинең капка төбенә килеп туктаган чакларын хәтерләп, елый башладым. Без барыбыз да җаныбызны айкаган сугыш гарасаты каршында калдык. Өйгә кайткач, апа әтинең сугыштан язган хатларын кулыма тоттырды. «Без бу хатларны инәйдән качып, мунча өйалдында елаша-елаша укый идек. Соңгы елларда бик сирәк очрашабыз… Син аны үзең белән ал… Багышла тимеркүкне Минтимергә… Ул да безнең әти төсле киң маңгайлы, куе кара кашлы… Мөгаен, ул – безнең агай-энебездер…» – диде. Шуннан соң мин Актүбәдән туры Казанга кайтып киттем һәм өйдә ялгызым бикләнеп, «Тимеркүк»не дүрт көндә тәмамладым. Язганда фани дөнья онытыла.

Язу мәхшәреннән арынып, әгәр йокыга киткән булсам, күзләремне ачып көн яктысын күрү белән, шөкер, димен. Аннан бисмилламны әйтеп, иман кәлимәсен укыйм, колак яфракларындагы, тамак төпләрендәге нокталарга җиңелчә генә баскалап, массаж ясыйм, салкын душ кереп, намаз укыйм. Ашыйсы-эчәсе ризыкларымны дога укып, алдан өшкереп куям. Бу – минем мәрт сәфәреннән алып кайткан гадәтем. Ә көнкүрештә балаларым ярдәмләшә.

:: Бүген сезне иң борчыган проблема нинди?

– Минем 2009 елдан бирле бернинди юллама алганым, шифаханәләрдә дәваланганым юк. Шулкадәр нык арыдым мин. Соңгы елларда кичергән авырлыклардан китеп торып, бераз дәваланасым, ял итәсем килә. Борчыган проблемалар буа буарлык. Алар барысы да хәрәкәттә. Бүген «Үлемсез полк» дигән зур роман-поэма язам. Аны тиз арада тәмамлап, ике повестемны да төгәлләргә дигән исәп тотам. Алар – төп әсәрләрем, аларны сузарга ярамый. Ә инде 2016 елда ук Татарстан китап нәшриятына илтеп тапшырган 6 томлык иҗатымның дөньяга чыкмавы, 90 яшьлек юбилеемны игътибарсыз калдырулары мине бик нык түбәнсетте. Шушы проблемалар – мәңгелек проблемалар инде ул…

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ГӨЛҮСӘ БАТТАЛОВА

АЛТЫНЧӘЧ

(ХИКӘЯ)

Казан күз яшьләренә ышанмый

– Саумы, Казан! Хәерле иртә!

Тулай торак бүлмәсенең Каравай базарына караган тәрәзәсен ачып җибәрдем дә шәһәр гүләвенә шушы сүзләремне өстәдем. Тугызынчы кат биеклегеннән юлланган сәламне трамвай тавышы үзенә йотты. Җилдә җилфердәгән алтын чәч бөдрәләрем битемне, күзләремне кытыклады, колак яфракларын назлады. Алтын чәч бөдрәләрем! Нәкъ шулай. Аксыл да, сары да түгел, алтын!

Бала-баладан авылдагы яшьтәшләрем мине «сары пошлак» дип үртәп килделәр. Ә мин, үз чиратымда, гарьләнеп: «Минем чәчем алтын! Алтын!» – дип такмаклый идем. Казанга имтиханнар бирергә киткәндә дә күрше малае: «Кая китте салам сыйрак, салам чәч?!» – дип көлеп калды. «Салам түгел, алтын!» – дип кабатладым эчтән, авылым белән саубуллаша-саубуллаша. Казан мине сары, кара, соры, ак, кызыл, җирән, хәтта яшел чәчле кешеләре белән каршы алды. Урам буйлап агылган гавамның, әлбәттә, минем чәчемнең төсендә эше юк иде.

...Шифоньер ишегендә көн күргән көзгегә карап, чәчемне тараган арада бүлмәне күздән кичердем: үтүк розеткага ялганган килеш калмаганмы, суыткыч ишеге ябылганмы, караватым пөхтәләп җыелганмы? Юкса ападан эләгәчәк. Усал ул минем. Авылдан Казанга – укырга керергә дип киткән кызларын эти белән әни студентлар тулай торагына якын да җибәрмәделәр. Алай-болай урлап китсәләр! «Самолет заводы»нда эшләүче туган тиешле апага ышанып тапшырдылар: эшчеләр торган тулай торак ни әйтсән дә тыныч була! Шәләй-вәләй йөрергә яраткан студентлар янына алма кебек кызны илтеп тыгып буламы, имеш! Апа ачы таңнан эшенә китә, мин көнозын берүзем имтиханга әзерләнәм. Рәхәтлек – акылдан язарлык! Шөкер, сынауларны ерып чыктым. Бүген укырга керүчеләр исемлеген эләчәкләр! Я мин Казан студенты булам, яисә сары пошлак тәкъдирен дәвам итәргә авылга кайтып китәм.

Бүлмә ишегеннән яшел чүәкләремне элеп, йөгереп чыкканда минем алтын бөдрәле башымнан җил кебек көн әнә шул уйлар үтте. Ачкычларымны сумкама ыргыттым да лифт төймәсенә бастым. Әй-лә, аскы каттан шул мыштырдавыкның менеп җиткәнен көтсәң! Баскычтан ике атлап, бер сикерәм лә мин...

Шушы җырны матур итеп, җырлыйлар
Әтнәләрдә...
Үзәкләремне өзәләр исемеңне әйтәләр дә...

Кинәт кенә аяклар мамыкка әйләнде. Тулай торак коридорының соры диварына сөялдем. Бәгырьдә нидер шартлап өзелде дә сулык-сулык сызларга тотынды. Кем җырлый? Кем җырлый бу җырны?! Күзне томан каплады, үпкәләр туган як җилен тансыклап кысылды – һава җитмәде. Битем буйлап (Казанга килгәч тәүге тапкыр!) күз яшьләрем тәгәрәште.

– Апаем, нишләп торараштай катып басып торасың?

Яшь пәрдәсе аша каршымда сулы чиләге белән швабрасын тоткан юантык кына ханым шәйләнде.

– Апа, сез дә Әтнәдәнме?

– Ниткән Әтнәдән булыйм, Аксубайдан. Синең, апаем, хәлең киттеме әллә? «Скорый»га дәшимме?

– Кирәкми, апа. Әтнә җырын җырладыгыз бит. Мин шул яклардан. Авылны сагындым...

Соңгы ике сүз минем болай да менә-менә түгеләм дип торган күңелне бөтенләй бәйдән ычкындырды. Кычкырып, тәмләп, рәхәтләнеп елап җибәрдем.

– Авылга кайтасым килә, апа...

– И, җүләр кызый. Нәрсә калган ул авылыңда? Ертык кәвешме? Укы, кеше булырсың! Казан күз яшьләренә ышанмый ул, шыңшыма. Синең яшьтә булсаммы, белер идем нишләргә. Әйдә, минем баскычны юып аласым бар, комачаулап торма, күзләреңне сөрт тә юлыңда бул.

– Апа, сез Әтнә көен ник җырладыгыз соң? Сез бит Аксубайдан дидегез.

– Телгә нинди җыр килмәс, вәт тинтерәтте бу. Менә Сарманны җырлыйм, кем мине туктата ала? Әйдә, бар, аяк астында буталма, кеше көлдереп, елап йөрмә...

Сарман буйларында яшел алан...

Кинәт кенә авырайган аякларымны сөйрәп, баскычтан төшеп киттем. Укырга керүчеләр исемлегенә эләкмәсәм генә ярар иде! Бүген үк авылга кайтып китәр идем. Яшәр идем әле салам чәч, сары пошлак булып. Моңа кадәр яшәлде бит. Акрын гына келтерәгән тугызынчы трамвай тәрәзәсенә башымны салып, мин әнә шуларны уйладым.

Чикерткә һәм яшел чүәк

Университетка килеп җиткәндә, беренче каттагы коридор кырмыска оясын хәтерләтә иде. Бөтен кеше исемлек көтә. Бөтен кешенең күзендә – өмет. Бөтен кешенең студент буласы килә! Ә нигә минем авылга кайтасым килә соң?

– Исемлек тагын ике сәгатьтән соң эленәчәк.

Деканаттан чыгып, әлеге хәбәрне җиткергән сәркатип кыз җансыз сынны хәтерләтте. Эчендә дә җаны юктыр, билләһи! Инде болай да көтеп, көтек булган мескен абитуриентларны тилмертмәсә!

– Бәлки, Ленин бакчасында көтәрбез? Киттекме?

Каршымда елмаеп торган егет ачуымны гына китерде. Татар әдәбиятыннан инша язганда бер партада утырган идек. Язма эшнең титул битен тутырганда: «Без фамилиядәшләр икән!» – дип әйтеп куюын ук өнәмәдем. Каян килгән КГБ агенты! Яратмыйм күзгә кылчык булып кергәннәрне!

Кырт борылдым да Университет урамыннан Бауманга төшеп киттем. Яшел чүәкле аякларым кызулый, йөгерә-атлый элдерәм генә – теге фамилиядәш куып җитсэ тагын! Кинәт шып туктадым да көлеп җибәрдем: «Кирәк ди аңа минем кебек сары пошлак!»

Ачык һавадагы җәйге кафега кереп утырдым. Көн эссе, кояш күрмәгәндәй кыздыра – монда ичмасам күләгә, җиләс.

– Вам что – чай, кофе или охладительные напитки?

Кафе хуҗасы, кассир, официант – бер үк кеше икән, минем кебек алтын чәчле апа.

– Миңа сөтле кайнар кара чәй.

– Сөт юк. Чәй булыр.

Менә бит татарча да аңлый лабаса. Ник бөтен кеше белән татарча гына сөйләшмидер. Җәй челләсендә кайнар чәй сораган үземне әйтер идем. Безнең әни: «Татарның тамыры буйлап кан түгел, чәй ага», – дип көлә... Әйе, минем әнием дә чәй ярата шул... Әллә нәрсәсенә күзләр тагын юешләнде. Ирексездән, аягыңа йомшак булыр дип, әни киертеп җибәргән яшел чүәкләремә карадым. Һәм... телсез калдым! Минем чүәккә... чикерткә кунган! Ничек? Казан үзәгендәме? Таш шәһәрдәме? Чикерткәме?

– Бәгърем, син кайдан килеп чыктың соң? Туган җирең кайда синең? Кайда синең яшел болының? Әллә... Әллә син дә, минем кебек, шәһәр шавында адашып калдыңмы? Авылың турында уйлаганда синең дә елыйсың киләме, чикерткә? Син минем яшел чүәкләремдә болын күрдеңме әллә? Сусыл яфрак дип белдеңме? И, җанашым... Исемлеккә эләкмәсәм, мин бүген авылга кайтып китәм. Казанны калдырып. Әйдә минем белән! Безнең авыл болыны кадәр матурлык беркайда юк!

– С вас 15 рублей.

Янәгыма чылтыратып җибәрделәрмени! Чәй өчен түләргә кушалар икән! Чәй онытылды инде! Чикерткә белән очраштык бит! Акча янчыгымны алырга дип букчама үрелгән идем, яңа җан дустым, ялт, чүәктән сикерде дә төште. Ашыга-кабалана 15 тәңкәмне түләдем дә Бауман урамына түшәлгән ташларга текәлдем: кайда минем чикерткәм? Их, мин бит аны бүген авылга алып кайтмакчы идем! Ә ул шәһәр ташы арасына кереп югалды...

Моңсу булып китте. Урам уртасында гитарада уйнап җырлаган абзыйның да көе моңсу.

Ланфрен-ланфра лан-тати-та...

Ник монда берәү дә татарча җырламый соң? Тулай торактагы теге апа төсле? Татарстан башкаласы лабаса Казан, ә Бауманда бер татар җыры юк. Йә, ярар, ярый җырламыйлар әле. Тагын елыйсы булыр иде.

Яшел чүәкләр мине урам буйлап алып китте. Ап-ак диварлары белән Кремль күренде. Ике атна Казанда яшәп, Сөембикә манарасын да барып күргән юк – мәктәп дәреслегендәге сурәте генә истә. Әнә бит ул авыш манара! Казан ханбикәсенең телсез шаһиты! Их, дип авыр сулап куйдым мин. Сөембикә ул, ичмасам, чибәр булган! Кара чәчле. Минем кебек түгел. «Сары пошлак. Татар кызлары кара чәчле була!» – дип, күпме ирештерделәр мине авыл малайлары. «Сары түгел, алтын, алтын!» – дип тәкрарлап елаудан артык китә алмадым. Аксыл чәчле татар кызы булмый микәнни?!

– Татарның асыл кызы син, балам... Аксыл чәчләрең, зәңгәр күзләрең затлы каныңа ишарә. Аллам сине яман күзләрдән сакласын...

Манара диварының ташларын сыйпап, дога пышылдаган әбинең миңа аталган сүзләреннән дертләп киттем. Уйларымны укыдымы әллә? Кем ул, мине кайдан белә? Мин бит әле беркемгә дәшмәдем, беркем белән бер кәлимә сүз алышмадым. Татар икәнем йөземә чыкканмы?

– Әмин, әби, рәхмәт яусын...

Карчык, гүя, мине ишетмәде дә. Куллары борынгы ташлардан шуышты, ә карашы... Карашы каядыр еракка төбәлгән иде аның. Еракка, еракка... Еллар үзенекен итсә дә, гүзәллеген югалтмаган йөз сызыклары, сөрмәле кара күзләре, биек маңгай, нәфис борын, кыйгач кашлар нидер турында әйтергә, без белмәгән, бәлки белергә дә тиеш булмаган серләр хакында сөйләргә тели иде кебек...

– Алтынчәч... Алтынчәч!

Сискәнеп, артыма борылдым. Миңа дәштеләрме? Мине Алтынчәч дип атадылармы?

– Алтынчәч! – Миңа таба кояш кебек балкып, фамилиядәш абитуриент егет килә иде. Мин әбигә таба кире борылдым. Күзләр таныш сынны эзләделәр. Сөембикә манарасының диварлары үксез калган кебек тоелды – бер мизгелдә әбидән җилләр искән иде. Әллә күземә күрендеме? Хыялым манара рухына җан өреп, күңелдә тергездеме әллә? Янә егет тавышы айнытып җибәрде:

– Без икебез дә исемлектә! Без синең белән Казанда бергә укыячакбыз, Алтынчәч!

– Ни дидең?

– Исемлек чыкты. Анда безнең фамилияләр бар!

– Кем дип атадың?

– Алтынчәч, дип. Чәчләрең... алтын бит!

– Кабатла, кем дидең?!

– Алтынчәч! А-л-т-ы-н-ч-ә-ч!!!

Кинәт бөтен Казан нурга күмелде. Ап-ак Кремль дә, Казансу да, Ленин дамбасы да... Алтын чәчләрем дә, яшел чүәгем дә... Минем өчен никадәр кадерле булган сүзне әйтүен әле аңлап та бетермәгән фамилиядәш егет тә...

Кочагымны җәеп, бәхетле язмышыма сөрән салдым:

– Мин сиңа килдем, саумы, Казан!

Рәфикъ ЮНЫС

Кайт әле, көз!

Кайда син, көз? Кайт әле, көз,
Кил әле, көз, булмаса!
Мин үзем – үзем түгелмен,
Күңелгә көз тулмаса!

Уйсыз җәй белән буталып
Күпме гомер узылган!
Ялт иттер юып – күңелгә
Күпме тузан утырган!

Сулык-сулык елар өчен
Су котә һәр уйсулык.
Сагындырды томаннарың,
Сагындырды моңсулык.

Сөйләшик әле озаклап,
Хыялда эреп бетеп.
Яңгырларың урман белән
Сөйләшкән кебек итеп...

Бар күңелдә нечкә кыллар –
Кагылганны көтәләр.
Анда синең йөрәк өзгеч
Җилләр генә үтәлә!

Яшәүнең тоям мәгънәсен.
Кабына сүнгән еллар.
Төннәреңә кергән саен,
Яктыра бара уйлар.

Кайда син, көз? Кайт әле, көз,
Кил әле, көз, булмаса!
Мин – мин түгел, тәнне – мунча,
Күңелне көз юмаса!

Бара имән

Табигатьтә дүртәр-бишәр
мең яшьлек агачлар да очрый.

Тыңла, кеше, гасыр җиле шаулый,
Шаулый яшел җилкәннәргә тулып.
Киләчәккә әнә бара имән
Җанлы-шаулы пирамида булып!

Җилфердәгән тормыш
әләмнәрен
Күтәрә ул һаман биеккәрәк.
Тылсымлы кан куып тора «Яшәү!»,
«Яшәү!» диеп типкән яшел йөрәк.

Һәр ботагы кыйный үлем рухын,
Һәр яфрагы әнә кояш имә.
Мең кул белән кочаклаган җирне,
Кочаклаган – аерырмын димә!

Дымлы җиле, яшел тыны белән
Сугара ул тормыш үзәннәрен.
Табалмассың сагыш, өметсезлек –
Ярып кара һәрбер күзәнәген!

Безгә әнә кулын изи бугай,
Ияртергә теләп үзе белән.
Әйтә бугай: «Нигә шулай җиңел
Килешәсең, кеше, үлем белән?!»

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры коллективы Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, театрның алыштыргысыз диктор-тәрҗемәчесе

Эльвира Хәниф кызы ШӘРӘФИЕВАның

вафат булуы турында хәбәр итә һәм мәрхүмәнең туганнары, дуслары, якыннарының авыр кайгыларын уртаклаша. Татар театрының талантлы хезмәткәре, сәнгатькә тугрылыклы булган дустыбызның якты истәлеге безнең күңелләрдә мәңге сакланыр.

Язучы фикере

ҮЗЕБЕЗ БЕЛГӘН КЕБЕК

Без инде бик белемле булып сөйләшергә яратабыз. Дипломнар белән уйнап карыйбыз. Кайчагында: «Әй, шуны да белмисенмени?!» – дип җиффәрәбез. Үзебезнең белемле булудан тәм табып яшибез, кыскасы.

Менә мин дә әллә нәрсәләр беләмдер кебек. Әллә кая китмичә генә, барыбызга да таныш булган нәрсәне алыйк әле. Җир. Җирнең түгәрәк икәнен беләм. Аның Кояш тирәли әйләнүен. Кояш системасында зурлыгы буенча өченче урында торган планета икәнен. Тагын әллә нәрсәләр.

Теләсә кем теләсә кайчан уятып сорасын, мин күз дә йоммыйча җавап бирә алам: «Җир түгәрәк... һ.б., һ.б...» Һәм уятып сораган кеше дә бу сүзләрне дөрескә исәпләп: «Вәт, маладис!» – дип баштан сыйпарга мөмкин. Баштан сыйпамаса да гаепләп булмый, моны белүче бер мин генә түгел ич. Бөтен кешенең дә башын тик түгел, гомерең җитмәс.

Без күп нәрсәләрне беләбез. Сорасалар-сорамасалар да, кеше маймылдан яралган, дип җавап бирәбез. Бергә берне кушсаң, ике була, дибез... Без – белемле кешеләр.

Әмма кайчак мин шикләнеп куям. Белемле соң бу? Менә дини китаплар бар, аларда, адәм туфрактан яратылган, диләр. Җирне яссы дип сурәтләгәннәре дә бар. Кит сыртында яки үгез җилкәсендә тора, дию бар. Һәм дингә ирелүчеләр моңа ышана. Алар өчен Җир, чынлап та, үгез сыртында тора. Тик без инде яхшы аңлыйбыз: алар надан, болай дип әйтүләре нигезсез, бу – белем түгел, бары тик ышану гына.

Ә без беләбез...

Тукта, ә мин кайчан күрдем әле Җирнең түгәрәк икәнен? Аның әйләнәсен соңгы тапкыр кайчан үлчәп карадым? Кояш системасына чыгып, Җирнең зурлыгын башка планеталар белән чагыштырып йөргәнгә дә хәтсез вакыт узган бугай. Хәтердә түгел. Бәлки, ул арада тагын берәр планета зуррак булып үсеп киткәндер?

Бактың исә, боларның берсен дә күргәнем юк икән бит. Әлбәттә, кемнәрдер күргәндер инде, кемдер тикшергәндер. Шул күргән кешеләр сөйли торгандыр. Ә мин алар сүзенә нигезләнәм, аларга ышанам. Шулай булгач, минем «белем» дип уйлаганы нәрсәләрем дә чын гыйлем түгел, ә ышану гына булып чыга.

Дини кешегә: «Җир яссы, ул үгез җилкәсендә тора, җир читенә чыгып аяк салындырып утырырга мөмкин», – диләр. Ул шуңа ышана. Ә миңа әйтәләр: «Җир түгәрәк. Бернинди үгез дә юк. Ул Кояш тирәли әйләнә». Мин шуңа ышанам. Ышанмый да булмый. Үгезе юк та юк инде аның. Булса, әллә кемнәр сүеп саткан булыр иде. Җир тиклем Җирне җилкәсендә тотарлык булгач, ите яхшы чыга дигән сүз бит инде ул үгезнең. Ә итнең бәясе әнә күпме тора!

Ярый, чурт с ним инде ул үгезе белән. Ә чынлыкта бит дини кешенең ышанулары да, безнең «белем» дә бер үк нәрсәгә нигезләнгән. Кеше сүзенә ышану ул. Һәр ике очракта да без үз акылыбыз белән ирешкән нәрсәләрне түгел, ә кемдер әйткәнне сөйлибез. Сөйләми дә булмый. Дәшмәсәң, надан дип уйлаулары бар. Ә чынлап та Җир түгәрәкме икән, әйләнәсе күпме икән, дип тикшеренеп йөрергә берәүнең дә җилкәсе кычытып тормый.

Шуңа күрә безнең һәр өлкәгә кагылышлы сорауларга җавап әзер. Үз акылыбыз белән ирешкән җавап түгел, әлбәттә. Кемнәндер ишеткән җавап. Фәлән фәннәр академигы Фәлән Фәләнов авызыннан ишетелгән сүзләр. Бездә әле сорау туганчы ук башыбызга сеңдерелгән сүзләр.

Һәм без уйлап та тормый җавап бирәбез. Үзебез белгән кебек.

Марат КӘБИРОВ

Өлге

Ярдәмлек сүз төркеме | Композитор ... Даутов | «Ролс-...» | Шагыйрә ... Янсуар

Казахстан каласы | Җәелеп, тармакланып үскән

... карлыгачы | Җырчы ... Зиннәт | Ивлин ... (инглиз әдибе)

Әле генә | Җайдак утыргычы | Япониядәге шәһәр

Ләкин, тик | ...-Анджелес

Язучы ... Галиев | Шабаев, Макаров | Җилкәнле, өч мачталы хәрби кораб | ... чабу, алкышлау | Актриса Виктория ... | ...-Бегас

Реактив двигательле очу аппараты

Фидель Кастро ... | Суга юл ачу | Актер Кирилл ...

Шарт теркәгече | Симезләр көрәше | Чалбарның бер төре

Җан | Балавыз (иск.) | Сизгер, уяу

Рәис Габдулла

Чәйне кайнар килеш саклый | Дөньяга килү

Акылсыз, юләр, аңгыра

24 сентябрь санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: шәрех, ПВА, сәмум, Филүс, вал, Эдгар, Ио, әкият, Манн, олуг, Вәсим, гобой, Хафизова, салам, Рем, атыла, Сен, шук. **Вертикаль буенча:** пуф, әрвах, Ивик, шасла, Илсаф, әүлия, Идрис, рамс, Том, Госман, Хәмәдинурова, гонг, балкыш, Лу, Рәми, йомгак.

Викторина

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерә аласыз.

1 «Ясаул» сүзе нәрсәне аңлата?
А) хан кызының ярдәмчесе;
Б) гаскәр башлыгы ярдәмчесе;
В) министрның элеккеге атамасы.

2 «Монда шундый гадәт бар икән: ашарга бирмәсәләр, үзеңә үрелеп алырга ярамый. Ит бирелгәч, махсус өстәл дә китерәләр. Аннары хан ит кисәген үзенең уң ягында утырган яраннарының берсенә бирде».
Әлеге өзек нинди тарихи чыганактан?
А) «Ибн Фадланның Идел буйлап сәяхәте»ннән;
Б) «Идегәй» дастаныннан;
В) XIII гасыр башында язылган «Кыйссаи Йосыф» поэмасыннан.

3 Алда китерелгән вариантларның кайсы милли вакытлы матбугат басмасы булып саналмый?
А) «Сәйяр»;
Б) «Игенче даны»;
В) «Кызыл Татарстан».

4 Эльмир Нәбиуллин – ...
А) «Ак барс» хоккей клубының элеккеге капкачысы;
Б) композитор;
В) футболчы.

**5 «Йа татар! вакыт җитте кузгалырга,
Мәгариф шәмгыданың кулга алырга;
Тәфәккерсез, гафил булып карап ятмый,
Вакыт йитте гыйлем, һөнәр кулланырга!»**
Бу шигырьнең авторы кем?
А) Габдулла Тукай;
Б) Мәҗит Гафури;
В) Мәүлә Колый.

Җаваплар: 1) Б; 2) А; 3) А; 4) В; 5) Б.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 17243 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 342

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73,
222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+